

КЫЙММӘТЛЕ КУЫШ

Ипотеканы ничә елда түләп бетерү отышлырак?

> 2

ХӘТЕР МӘҢГЕЛЕК

«Үлемсез полк» акциясе быел яңача узачак

> 2

103 ЯШЬЛЕК ВЕТЕРАН:

«Чын яшемне әйтсәм, аптырарсыз!»

> 5

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Балалар һәм ата-аналар өчен махсус сәхифә

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 64 (29031) | Шимбә | 6 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ҮЛЕМ ҺӘМ ҮЛЕМСЕЗЛЕК

er.ru

Ватан хакына

Инде менә ничә ел, Җиңү көне якынлашканда Равил Фәйзуллинның «Хәтер» дигән шигырен искә төшерәм. Быел андагы: «Әй, син, хәтер, гомер язларыннан Безнең яшьлекләрне чакырып ал!» – дигән юллар аерым бер мәгънәгә ия кебек. Илгә Җиңү яулаган Ватан улларының сафлары еллап түгел, айлап сирәгәя. Тарихыбыздагы олы вакыйганың тере шаһитлары бакыйлыкка күчә барганда, шаһит булып бары тик хәтер кала. Әмма саклап, әледән-әле яңартып тормасаң, хәтер дә гомерлек түгел.

Менә бүген кайчандыр очрашкан, алардан сугыш хәлләрен сөйләткән ветераннарны күңелдән барлап утырам. Инде аларның күбесе вафат. Ярый әле «яшьлекләрен чакырып алырга» хәтер бар. Ярый әле алар турында язганнарым сакланган.

Бөек Җиңүнең 70 еллыгына якташым, элемтә оешмасында эшләүче Марат Корбанов миңа әтисе Габделнур турында бер гыйбрәт сөйләгән иде. Телевизордан сугыш турында фильм караганда, гел елый торган булган Габделнур солдат. Ни өчен елаган? Моны Марат берничек тә аңлата алмады. Әтисе дә берни дәшмәгән, сөйләмәгән, сүзсез генә елаган. Юкса Украина, Венгрия, Польша, Чехословакияне азат иткән, үлем белән ничә тапкыр күзгә-күз очрашкан солдат елыйсын елап бетергән, күңеле таш булып каткан булырга тиеш иде кебек. Үземчә болайрак уйлаган идем ул чакта: Габделнур солдат, мөгаен, сугыш мәхшәрләрен, һәлак булган дусларын оныта алмыйдыр. Алар ятса – төшендә, торса – исендәдер. Марат сөйләгән бер вакыйганы мин дә оныта алмыйм әле.

Бервакыт дошман безнекеләрне бомбага тота башлый, солдатлар кайда чокыр бар – шунда сыена. Габделнур күрше Ияш авылы егете Галимҗан белән юл кырыендагы чокырга каплана, янәшәдә генә шартлаган бер бомба Габделнурны балчык белән күмеп ташлый. Аяк-кулларын селкетә-селкетә балчык астыннан чыга бу. Карасa, янәшәдә генә Галимҗанның ярты гәүдәсе ята, гәүдәнең башка өлешләре тирә-якка сибелгән. Шуларны берәм-берәм җыеп алып, якташын үз куллары белән җирләргә туры килә Габделнурга. Бу вакыйганы еш искә ала торган була ул, димәк, тәмам бәгырьләренә тигән. Кино караганда, бәлки, шул искә төшеп, күзләре яшьләнә торган булгандыр Габделнур солдатның.

Бу язмамны укучылар арасында Габделнурның, Галимҗанның туганнары йә аларны ишетеп белгән кешеләр булса, шулар рухына дога укырлар, алар турында балаларына сөйләп, хәтер озайтырлар дип өметләнәм. Батырлар рухын буыннан-буынга тапшыру кирәклеге турында сүзләр соңгы вакытларда бигрәк тә куерды. Җитәкчелек яшь буында патриотизм хисләре тәрбияләү кирәклеген әледән-әле искә төшерә. Мин Марат Корбановтан: «Әтиең белә торып үлемгә ничек китте икән?» – дип сораган идем. Марат исә: «Әти үләргә түгел, җиңәргә киткән. Ул чорда патриотик тәрбия бик көчле булган. Әти генә түгел, ул чактагы тәрбия белән үзем дә, сугышка китеп, дошман амбразурасын күкрәгем белән каплаган булыр идем», – дигән иде. Безнең һәркайсыбыз – җәмгыять җимеше.

Көндәлегемне актарып утырганда, тагын бер гыйбрәтле генә язмага тап булдым. 2020 елның 27 гыйнварында Советлар Союзы Герое Борис Кузнецов янына барганмын икән. Ни сөйләгәннәрен язгалап та барганмын, шактый сүзләре хәтергә дә уелып калган. Мин аның 15 яшеннән хәрби комиссариат бусагаларын таптый башлавына гаҗәпләнеп утырган идем. Егетне: «Башың яшь әле», – дип, кире борып җибәрә торганнар, ә ул тагын килә торган. Ниһаять, 16 яшендә хәрәкәттәге армиягә алганнар Борис Кирилловичны. «Озын гәүдәле, бер центнер авырлыкта идем, бәлки, шуңа күрә алганнардыр», – дигән иде ул. Борис Кузнецов хәрәкәттәге армиядә иң яшь солдат була, ә 17 яшендә аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Хәер, бу хакта белми дә әле ул, төрле бәрелешләрне хәрби бурыч үтәү дип кенә кабул итә. Алтын Йолдызны аңа 18 яшь тулгач кына тапшыралар. Днепрны кичеп, уңъяк ярда ныгып калып, безнең гаскәрләргә елга кичәр өчен ничек итеп шартлар тудырганнарын бик яхшы хәтерли әле Борис Кузнецов.

Армия штабында иң тәҗрибәле, иң әзерлекле 40 кешене сайлап алалар. Ни өчендер, иң яшь һәм тәҗрибәсез Борис та шулар арасына эләгә. Днепрны төнлә йөзеп чыгалар егетләр. Немецлар боларны күреп ала да ут ача. Ике көн эчендә ротадан нибары дүрт кеше исән кала. Патроннар, гранаталар бетә. Шуннан соң шушы дүрт кеше: «Ватан өчен! Сталин өчен!» – дип, һөҗүмгә ташлана. Кул сугышы башланып китә. Шулвакыт Борис немец пушкасын күреп ала да шуннан дошманга ут ача, берничә танкны, дистәләгән солдатны юк итә. Тик бераздан янында граната шартлап, аңын югалта егет. «Бер атнадан кыр госпиталендә аңыма килгәнмен, бөтен тәнемдә ярчыклар иде», – дип сөйләгән иде ул. Дөресен әйткәндә, мин аның сүзләрен башта ышаныр-ышанмас кына тыңладым. Каян килгән 17 яшьлек егеткә шундый кыюлык?

«Курку хисе башка кереп тә карамады, – дигән иде ул. Бүгенге тәрбиядән дә, бүгенге яшьләрдән дә зарланмады Борис Кириллович. – Батырлыкка бару рухы бездә һаман яши әле», – дип тә куйган иде.

Миңа Газинур Гафиятуллинның хатыны Гыйльмурый әби, аның улы Әнвәр белән дә очрашырга насыйп булды. Гыйльмурый әби, 103кә кадәр яшәп, берничә ел элек кенә вафат булды. Әтисе сугышка киткәч туган Әнвәр абый, шөкер, исән-сау әле, быел аңа 82 яшь туларга тиеш. Телефон аша хәбәрләшеп торабыз. Әтисенең дошман амбразурасын күкрәге белән каплавын шулай тиеш булган дип кабул итә Әнвәр абый. Ә Газинурның әтисе Гафиятулла абыйның әйткәннәрен, моңсу гына елмаеп, еш искә алалар. Улының һәлак булуы турында ишеткәч, Гафиятулла абзый: «Бөтен җирдә беренче булырга тырышты, «безбашка» иде, үзе турында уйламады, малайны шул харап иткән дә инде», – дигән, имеш. Аның әйткәннәре, бәлки, сүзгә-сүз түгелдер дә, әмма асылы шул: иң элек башкалар турында кайгыртып яшәве Газинурны үлемгә һәм... үлемсезлеккә атларга этәргән.

Җиңү көне – күзләргә яшь, күңелләргә горурлык хисләре тула торган бәйрәм. Җырлана торган җырларыбыз да моңсулык катыш шатлыклардан тора. Бүген дөньялар тыныч түгел. Минем Советлар Союзы Герое Борис Кузнецов белән очрашуым соңгысы булган икән. Ул шуннан соң озак яшәмәде. Украина тирәсендә барган хәлләрдән шул вакытта ук шактый хәбәрдар булган героебыз. Бүген мин аның кайбер сүзләрен хәтта әүлиялык дип кабул итәм.

– Зур сугыш булмас. Ике елдан без иң көчле дәүләткә әйләнәчәкбез, менә күрерсез, – дигән иде ул. Көчле булырга, тыныч яшәргә язсын. Шул ук вакытта, Равил Фәйзуллин үзенең «Хәтер» шигырендә язганча, «Безнең гомерләрдә кайтмый калганнарның хакы бар» икәнен дә онытмаска иде.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

	2015	2023
Сугыш инвалидлары	1148	59
Сугышта катнашучылар	2441	172
Хәрәкәттәге армия составында булмаган хәрби частьларда хезмәт итүчеләр	805	68
Концлагерьларның элеккеге балигъ булмаган тоткыннары	224	102
«Ленинград камалышында яшәүче» билгесе белән бүләкләнүчеләр	239	95
Тыл хезмәтчәннәре	67866	10218
Сугышта катнашучыларның һәм сугыш инвалидларының тол хатыннары	4116	3563
Барлыгы	76839	14277

ҖИҢҮ КӨНЕ БЕЛӘН!

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгы уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Сезне Бөек Ватан сугышында Җиңү көне уңаеннан чын йөрәктән тәбрик итәм!

Әлеге олы бәйрәм көннәрендә без киләчәк буыннарга тыныч тормыш һәм азатлык китергән күпмилләтле совет халкының каһарманлыгы алдында баш иябез.

Җиңү коточкыч зур корбаннар бәрабәренә яуланды. Сугышның утлы дәһшәте һәрбер йортка, һәрбер гаиләгә кагылды. Республикадан гына да фронтка җиде йөз мең кеше китте, шуларның яртысыннан күбесенә туган нигезенә әйләнеп кайту насыйп булмады.

Муса Җәлил, Михаил Девятаев, Мәгубә Сыртланова, Петр Гаврилов, Гани Сафиуллин, Николай Столяров, Гази Заһитов, Алексей Исаев, Сабир Әхтәмов, Михаил Симонов, Фәрит Фәтхуллин, Борис Кузнецов һәм тагын бик күпләрнең тиңдәшсез батырлыклары ил тарихына мәңгелеккә язылды.

Канкойгыч орышта, бомбага тотудан, миналар шартлаудан һәлак булган, концлагерьларда җәзалап үтерелгән, авыр яралардан, ачлыктан вафат булган сугыш корбаннары турында хатирәләр – безнең өчен һич төзәлмәс ачы җәрәхәт. Фашист илбасарлары һәм аларның куштаннары җинаятьләрен, тыныч халыкны вәхшиләрчә газаплауларын без һич онытырга һәм кичерергә, нацизмны тергезүгә юл куярга тиеш түгел!

Җиңүне якынайту өчен завод станоклары янында, колхоз кырларында һәм конструкторлык бюроларында алны-ялны белмичә эшләгән тыл хезмәтчәннәре, госпитальләрдә яралыларны дәвалаган табиблар, ил сакчыларының сугышчан рухын күтәрү өчен тырышлык куйган сәнгать әһелләре шулай ук олы ихтирамга лаек.

Вакыт агышын туктатып булмый. Еллар узган саен ул вәхшәтле сугышта катнашучылар, аның шаһитлары арабыздан китә бара. Шуңа да бүген исән ветераннарыбызга карата хөрмәтебез тагын да арта. Аларның Ватанга тугрылыгы, корычтай ихтыяры һәм ныклыгы – безнең өчен күркәм үрнәк.

Бүген дә җиңүчеләрнең варислары заман сынауларына каршы тора, вөҗдан кушканча илебезне яклап, тарихи дөреслек хакына неонацизмга каршы көрәшә.

Хөрмәтле татарстанлылар!

Бу тантаналы көннәрдә безне Бөек Ватан сугышы турында хатирәләрне һәм хакыйкатьне сакларга омтылышыбыз, шул данлы еллардагыча дошманны тар-мар итеп, Җиңү яулауга ышанычыбыз берләштерә.

Җиңү көне киләчәктә дә безнең өчен һәм барлык киләчәк буыннар өчен рухи һәм әхлакый маяк буласына шигем юк.

Сезнең һәрберегезгә бәхет һәм иминлек телим!

Бөек Җиңү көне котлы булсын!

Эсседән соң – юеш кар

Атна ахырында Татарстанда һава торышы бозыла. Төнге сәгатьләрдә һава температурасы +1 градуска кадәр төшәчәк. Урыны белән юеш кар яварга мөмкин.

Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, якшәмбе – 7 майда Урта Идел төбәге циклон йогынтысында калачак. Республикага төньяктан салкын һава агымы үтеп керү сәбәпле, суыта. Көндез термометрның төрекөмеш баганасы +8...+13 градуска кадәр күтәрелсә, төнге сәгатьләрдә +1...+6 градуска калачак. Секундына 15 метрга кадәр көчле җил. Урыны белән яңгыр, кайбер районнарда юеш кар көтелә.

vk.com

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Тарихсызлык – затсызлыкмы?

Белемнең акча эшләргә яраклысын гына белем санаучылар күбәйгән заманда яшибез. Шул җәһәттән, ни кызганыч, халыкның күпчелеге тарих белән артык кызыксынмый, диясе килә. Алган тар белгечлек кысасындагы белем дөнья куганда җитеп арткан, дип саный гавам. Мәктәптә үткән тарихтан да аерым вакыйгалар һәм даталар (мәсәлән, Бөек Ватан сугышы еллары, Гагарин галәмгә очкан көн һәм ел, яисә Октябрь инкыйлабы елы), кайбер вак эпизодлар гына кеше хәтерендә. Танышларымның кайберләреннән гади генә даталарны – Икенче Бөтендөнья сугышы башланган һәм беткән ел һәм көннәрне сораганым бар. Көннәрен белүчеләр шактый сирәк, елларга килгәндә, башлану вакытын гел Бөек Ватан сугышы башланган ел белән бутыйлар.

Үзебезнең – татарның тарихы дигәндә, Казан алынган елны белүчеләр дә артык күп димәс идем. Кая ул Болгар чоры, Алтын Урда тарихы, андагы даталар, шанлы вакыйгалар… Республика төзелгән елны, ул эштә башлап йөргән шәхесләрне дә, йөз еллык юбилей үтүгә, инде онытып маташалар.

Мондый хәл дөресме? Миңа калса, аз гына да дөрес түгел. Без бит – кеше затлары. Бәс шулай икән, нindидер минималь гыйлем һәрберебездә булырга тиеш дип беләм. Ярар, катлаулы саналган фән – философияне белмик. Чит телләрдә дә сөйләшмик. Йолдызлар белән планеталарны да астрономнарга калдырыйк. Нindидер квант физикасы белән дә бары галимнәр генә шөгыльләнсен. Тик менә тарих дигәнебезнең урыны аерым. Тарих белән җәмгыять белемен адәми зат белергә тиеш. Чөнки нәкъ менә үткәнне белмәгәнгә, бүгенгебез куанычлы түгел безнең. Үзебезнең милләтне генә күз алдында тотуым түгел, гомумән әйтәм. Татар тарихына кайтканда, бигрәк тә шуны ассызыклыйсы килә: аны һәркем билгеле бер дәрәҗәдә белгән тәкъдирдә генә безнең милли үзаң тиешле югарылыкка менә ала. Ә милли үзаң сайлыгы – безнең халыкта, миңа калса, иң җитешмәгән сыйфатларның берсе. «Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк» дигән тапталган сүздән дә бигрәк, үз тарихын өйрәнгән милләт кенә чын милләт булып җитешә, үзен саклый, яклый ала, диясе килә. Гомумән, кеше дигәнең Җиргә кеше булып яшәргә килгән икән, милләт тарихын да, ил тарихын, бөтендөнья тарихын да билгеле бер күләмдә белергә тиеш. Башка фәннәрне тар белгечләргә калдырырга була, тарихны – юк!

Тарихны белгәндә, гомуми наданлык кимү – бер хәл, андый очракта барыннан да бигрәк бүгенгене, бүгенге вакыйгаларны дөрес бәяләү мөмкинлеге арта. Киләчәкне хәвефсез итү турында әйткән дә юк. Андый гыйлемнең активлыкны, кешедәге гражданлык позициясен бер башка көчәйтүен дә билгелисе килә. Тарихи белем ул – халыкның затлылык күрсәткече. Кеше дигәнең, мәсәлән, Октябрь инкыйлабының сәбәпләрен, аның илгә, дөньяга нәрсә китергәнен, гомуми нәтиҗәләрен белә икән, ул инде соры масса эчендә кала алмый. Ул шул вакыйганың булса да асылына төшкән, аны аңлаган дигән сүз. Тик күпләр үзләренең ялкау аңын гомуми белемнәр белән тулыландырырга иренә, вакытын мөлкәт, акча артыннан чабып үткәрә, рухи байлык туплауның әһәмиятен, тәмен аңламый. Тарих хакында сөйләшкәндә, кайберәүләрдән хәтта «скучно» дигән кәлимә дә ишетәсең. Ул чагында нәрсә «не скучно» соң? Очсызлы телесериалларымы? Әллә «Мужское-женское» ише ток-шоуларымы? Кеше үзенең затсыз кызыксынуларыннан (мәсәлән, җилбәзәк кавем – артистлар тормышы), кемнәрнеңдер урын-җир пычрагыннан йөз чөерә белгәндә генә тарих кебек фәнне, аның кадерен, әһәмиятен аңлый алачак.

Тагын бер кат искәртәсе килә: тарихны белүдә олы зарурлык бар. Чөнки башка бер генә фән дә тарих кебек киләчәк өчен җаваплылык тәрбияли алмый. Тарих кына (сүз объектив, чын тарих турында бара) үткәндә күпме ялгышлар ясалганын, аларның сәбәпләрен ачып бирергә сәләтле. Тарихны тиешенчә белеп, аннан сабак алып яшәмәү ул – дәһшәтле үткәннәрне кабат чакыру гына түгел, аларны гарантияләү дә.

Бүгенгене, хәзерге көнне карыйк. Зурдан алганда ул – үткән еллар, дәверләр нәтиҗәсе. Кайдадыр канкоеш бара икән, димәк, үткәндәге бөек фаҗигаләрне онытканбыз. Нәрсәнедер яхшыртасы килеп, тарихта күпме начарлыклар кылынган. Үткәннәребездә «гүзәл киләчәк хакына» дип, күпме саташулар, күпме тәгълиматлар, күпме ашкынулар аша үтелгән. Без көткән «гүзәл киләчәк» яралмады гына түгел, ул юлларга миллионлаган корбаннар салынды. Үткән XX гасырда, без яшәгән илдә – Россиядә бар кешене дә тигез итәчәк гадел җәмгыять хакына җиде дистә ел буе барган олы сәяси-икътисадый тәҗрибәне искә алу да җитә. Киләчәк бәхет хакына күпме кан, җан коелды, ГУЛАГлар эшләде. Бары гасыр азагы җитәрәк кенә безне бәхетле итәргә тиешле коммунизм тәгълиматының бер утопия, саташу икәне аңлашылды. Тик азаккача барыбер аңлап бетермәдек. Бүген тагын шул тәртипләргә ымсынучылар, тимер кул белән урнаштырылган «тәртип»кә сусаучылар күбәйде. Бу хәл нәрсәне аңлата? Бу тагын да «Тарихның төп сабагы шул: аннан сабак алынмый» дигән мәгълүм максиманы һәм гавамдагы наданлыкны аңлата. Бары наданнар гына бер баскан тырмага кат-кат китереп баса…

Экрандагы тыйнаксызлык, ипсезлек сәбәпле, телевизорга мәхәббәт бөтенләй диярлек булмаса да, кай чагында телевизион каналларны барлап чыккан чаклар була. Гадәттә, мин аннан тирә-якны танып белергә өйрәткән (познавательный) тапшырулар эзлим. Табигатькә, сәяхәтләргә кагылышлылары бөтенләй юк, дип әйтеп булмый. Тик менә тулысынча тарихка (илнекеме ул, дөнья тарихымы), багышланган канал таба алганым юк. Фәкыйрегез инде күптән, татарча каналлар арасында да үткән тарихыбызны яктырткан, пропагандалаган аерым канал булса иде, дип хыяллана. Тик, кая безгә – каткан тезгә, дигән кебек, үзе үк хыялның тормышка ашасына артык ышанмый. Ярар, аерым канал булмасын да. Тик менә булганнарында тарихыбызга кагылышлы тапшыруларны бермә-бер арттырырга кем комачаулый? Бездә Мәрҗани исемендәге Тарих институты, КФУда тарих-филология факультеты бар. Андагы галимнәр тапшырулар алып барырга каршы түгелләрдер дип уйлыйм. Тарихыбызны көн-төн дигәндәй тукып, сөйләп торасы иде милләтебезгә. Татар ул-кызлары белсен, горурлансын иде үткәннәребез белән. Тарих ул – белем генә түгел, ул – тәрбияче дә, рухи, әхлакый үсеш тә бит әле.

ХӘТЕРЛӘҮ ЧИКЛӘНМИ

kzn.ru

Бәйрәмне каршылап

Билгеле булганча, быел Россиядә традицион «Үлемсез полк» йөреше булмаячак. Аның урынына хөрмәт һәм хәтерләү акциясен башкача оештыру күздә тотыла.

Яңача

«Үлемсез полк»ны оештыруга үзгәрешләр кергәне бар иде инде. Исегездә булса, коронавирус пандемиясе чорында аны онлайн рәвештә үткәрделәр.

2023 елда «Үлемсез полк» акциясе кысасында ветераннарның фотосурәтләрен футболка, толстовкага төшерү һәм бәйрәмгә шуны киеп килү тәкъдим ителде. Мондый формат яшьләр арасында аеруча популяр булыр дип көтәләр. Моңа өстәп, акция кысасында якыннарның фотосурәтләрен түштамгага яисә махсус бейджга урнаштыру да хуплана.

Моннан тыш сугышта катнашкан кешеләрнең фотосурәтләрен автомобильләрдә урнаштырырга да мөмкин. Моның өчен штраф салмаячаклар. Иң мөһиме – фотолар машина йөртүчегә комачауламаска тиеш.

Социаль челтәрләрдәге шәхси сәхифәләрдә дә Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләрнең сурәтләрен куярга тәкъдим ителә. «Үлемсез полк»ның рәсми сайтында да (www.moypolk.ru) хәтерләү һәм хөрмәтләү акциясенә кушылырга мөмкин.

Бушлай бастырып бирәләр

«Үлемсез полк»та файдаланыла торган фотосурәтләрне республиканың күпфункцияле үзәкләрендә бушлай бастырырга мөмкин булачак. Фотосурәтләрне электрон рәвештә дә, гаилә альбомыннан да кабул итәләр. Теләгән кешеләргә аларны А4 форматындагы тематик рамкага урнаштырырга да ярдәм итәчәкләр. Бушлай хезмәттән 6 нчы майга кадәр файдаланырга мөмкин. 7–9 май көннәрендә үзәк офислары эшләми.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре татарстанлыларга «Җиңү йөзләре» проектында катнашуда да ярдәм итәргә әзер. Биредә дә фотосурәтләр кулланыла. Проектның тарих сайтына фото урнаштырганда, ветеран хакында кайбер мәгълүмат та бирергә кирәк. Хәзергә «Җиңү йөзләре» сайтында 850 меңнән артык фронтовик һәм тыл хезмәтчәне тарихы саклана.

Сәламәтлек

Мәкерле чир

Роспотребнадзор белгечләре кызамыкның яңа билгеләре пәйда булу турында кисәтә.

Әлеге чирне йоктырган кешенең йөзе, күз кабаклары да шешәргә мөмкин, ди алар. Кызамыкның калган билгеләре исә, нигездә, ОРВИныкына охшаш. Беренче көннәрдә ютәл борчый, тамак авырта, борынга томау төшә. Әмма кызамык башлануның дүртенче көнендә тәнгә кызыл тимгелләр чыга башлый. Ул тиз арада тарала, артканнан-арта бара.

Белгечләр республикада кызамыкка бәйле вазгыятьне киеренке дип бәяли. Ел башыннан бирле Татарстанда кызамык йоктыруның 46 очрагы теркәлгән. Шуларның 20се – балалар. Хәзерге вакытта республикада алар белән элемтәдә булган 12 меңнән артык кеше исәпләнә. Республикада теркәлгән кызамык очракларының 80 проценты Татарстанга читтән килүчеләрдә ачыкланган. Аларның күбесен республикага Таҗикстаннан эшкә килүчеләр тәшкил итә. Араларында Новосибирск, Мәскәү, Мисыр һәм Бурятиядән килүчеләр дә бар.

Роспотребнадзор идарәсе белгечләре кызамыкны яшен тизлегендә таралучы бик мәкерле һәм куркыныч чир, дип кисәтә. Хәтта коронавирус та шулкадәр тиз йокмый, ди алар. Кызамык йоктырган кеше белән аралашкан булсаң, 100 процент очракта үзең дә авырый башлаячаксың.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов сүзләренә караганда, кызамыктан фәкать вакцина ярдәмендә генә сакланып була. Узган атнада республика хастаханәләренә кызамыкка каршы вакцинаның чираттагы партиясе кайтты. Аны, иң беренче чиратта, бу чир белән бер тапкыр да авырмаган, аңа каршы прививка ясалмаган яки бер генә прививка ясалган кешеләр кадатырга тиеш. Башка очракларда ул календарь буенча ясалса, авыру белән аралашкан кешегә, яшенә карап тормастан, тиз арада ясалырга тиеш.

– Илкүләм прививкалар календаре буенча, 55 яшькә кадәр кешегә кызамыкка каршы ике прививка ясалган булырга тиеш. Ул аңа гомере буена җитә. Бу прививкалар документ нигезендә теркәлгән булырга тиеш. Әгәр кеше үзенә кызамыкка каршы прививка ясалганмы-юкмы икәнлекне төгәл белмәсә, ул моңа тәгаен инанып өчен эхинококка IgG антитәнчекләр анализы тапшырырга тиеш. Әгәр кешенең бу чиргә каршы иммунитеты юк икәнлеге ачыкланса, аңа кызамыкка каршы ике прививка ясатасы булачак. Ике прививка арасында өч ай вакыт үтәргә тиеш, – ди баш эпидемиолог.

Белгечләр, кызамык белән авырып терелгән кешедә җитди өзлегүләр дә күзәтелергә мөмкин, дип кисәтә.

– Кызамык белән авырганнан соң, өлкәннәрдә пневмония, менингит башланырга, аякларны көзән җыерырга мөмкин. Кызамык бөерләргә дә бәрә. Балаларның хәле тагын да аянычрак тәмамлануы бар. Ник дигәндә, кызамык аркасында баланың баш мие тулысынча ялкынсынырга (панэнцефалит) мөмкин, – ди Лопушов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ИПОТЕКА АРТКА СӨЙРИ

Соңгы бер елда 30 елга ипотека рәсмиләштерүчеләр саны ике тапкыр арткан. Шунысы да бар: «сакаллы» ипотека алырга теләк белдерүчеләрнең күбесе, банкка әҗәтен түләп бетергәнче, пенсиягә чыгу яшенә җитәчәк. Бурычлы үлмәсме? Әллә ипотеканы озак вакытка алып, аны тизрәк түләп бетерү отышлымы? Без әнә шул сорауларга ачыклык кертергә тырыштык.

Билгеле булганча, бүген илдә ипотеканы күп дигәндә 30 елга рәсмиләштерергә мөмкин. Түләү вакытын сузган саен, процентларга бәйле бурыч күләме дә арта, билгеле.

– Ипотека рәсмиләштерергә теләүчеләрнең гаризаларын тикшергәндә, аларның кредит тарихы, түләү сәләте һәм айлык кереме исәпкә алына, – ди башкаладагы банкларның берсендә эшләүче кредит белгече Альбина Дорофеева. – Әнә шул мәгълүматлардан чыгып, ипотека кредитының ставкасы һәм срогы билгеләнә. Ипотека буенча түләү гаиләнең яки ялгыз яшәүче кешенең айлык кеременең 40–50 процентыннан артмаска тиеш. Гариза тапшыручының яше дә исәпкә алына. Ипотека буенча соңгы кертемне түләгәндә 70–80 яшькә җитәчәк кешеләргә озак вакытка исәпләнгән ипотека рәсмиләштермибез, билгеле. Азрак вакытка алган очракта айлык түләү зуррак, ә банктан алган акчага өстәп кайтарган бурыч күләме азрак була. Ипотеканы озаграк вакытка алсаң исә киресенчә.

Сан

2022 елда Татарстанда яшәүчеләр **156,4** миллиард сумлык **46,5** мең ипотека кредиты рәсмиләштергән.

Мисал китерик. *Фәлән шәһәрдә яшәүче Галиевларның айлык кереме –* ***70*** *мең сум, ди. Балалары юк.* ***5*** *миллион сумга ипотекага фатир алмакчылар. Беренчел кертемгә* ***1*** *миллион сум акчалары бар. Ипотека ставкасы –* ***10*** *процент.*

- *Ипотеканы* ***10*** *елга алсалар, айлык түләү –* ***52*** *мең сум, бурычка өстәп кайтарасы акча –* ***2,3*** *миллион сум.*
- *Ипотеканы* ***30*** *елга алсалар, айлык түләү –* ***35*** *мең сум, процент итеп түлисе акча –* ***8,6*** *миллион сум.*

Россия Үзәк банкы мәгълүматларына караганда, былтыр барлык ипотека кредитларының 40 проценты 30 елга дип алынган. Алдагы елны мондый гаризалар саны икеләтә кимрәк теркәлгән. Озак вакытка ипотека рәсмиләштерүчеләр – нигездә 35–45 яшьлекләр. Димәк, әҗәтләрен түләп бетергәндә, пенсия яшендә булачаклар. Банк белгечләрен әнә шул борчуга салган да инде. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, узган ел ипотека рәсмиләштерү өчен куллану кредиты алучылар саны да икеләтә күбрәк теркәлгән. Хәлләр алга таба да болай дәвам итсә, кредит оешмаларына финанс куркынычы янарга мөмкин, дигәннәр.

Гади халыкның хәле аңлашыла, ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин.

– Бүген торак бәяләре кыйммәт. Халыкның кесә ягы исә бик чамалы. Акчасы булганнар аны урнаштыру җаен кайгыртып куйды инде. 30 елга дип ипотека рәсмиләштерүчеләр – кесәсе такыр булганнар. Өстәвенә иртәгәге көнгә ышаныч та юк. Мондый шартларда бар булган акчаны тотып бетерергә ярамый. Шуңа күрә халык ничарадан бичара дигәндәй, «сакаллы» ипотекага ризалаша да инде. Мәсьәләне чишүнең бердәнбер ысулы – торак бәясен төшерү. Ә моның өчен бөтен шартлар бар. Белүебезчә, Казанда төзелеш оешмалары яңа йортлардагы фатирларны төзелешкә киткән чыгымнардан икеләтә кыйммәтрәк бәягә сата.

Банк белгече әйтүенчә, кредит оешмасыннан алган бурычны вакытыннан алдарак та кайтарып бирергә мөмкин.

– Канун нигезендә теләсә нинди кредитны, шул исәптән ипотеканы да, иртәрәк түләп бетерергә ярый, – ди Альбина Дорофеева. – Тик моның бер шарты бар: бу хакта банкка алдан хәбәр итәргә кирәк. Әҗәтне өлешчә капларга телисез икән, банк түләү графигын яңадан исәпләп бирәчәк. Беренчедән, ипотека срогын киметергә мөмкин. Бу очракта, айлык түләү артачак, ә процент өлеше кимеячәк. Шуңа күрә бу – иң отышлысы. Ягъни калган суммага процент азрак исәпләнәчәк. Икенчедән, айлык түләүне киметергә була. Тик шунысын истә тотыгыз: бу очракта сез түләгән акчаның күп өлеше процентларны каплауга, калганы гына төп бурычны түләүгә тотылачак. Ипотеканы вакытыннан алда ябу отышлымы-юкмы? Бу сорауга төгәл җавап юк. Мәсәлән, ипотеканы түли генә башлаган елларда акчаның күп өлеше процент түләүгә тотыла, ә соңгы елларда исә бурыч кына капланып бара. Шуңа күрә ахырга таба артык кабалануның файдасы да шулкадәр генә.

Эльвира ВӘЛИЕВА

СЫЕР АСРАП, БАЕП БУЛА

Авыл тормышы

Тәтеш районының Байраш авылында яшәүче Тәнзилә Йосыпова әнә шулай ди. «Файдасы юк», – диючеләргә аның – үз дәлиле. Кызык, үзләре әлеге муллыкка ничек ирешә икән?

Йосыповлар хуҗалыгына килеп туктагач, берәр бай өедер бу, дип уйлаган идек. Ике катлы йорт, кирпечтән ясалган заманча койма, яхшы машина… Тик капка төбендә ашлык тутыручы ирләрне күргәч, җир кешеләре икәнлеген аңладык. Малларына азык кайтарткан булганнар икән. Әтиле-уллы урамда капчыкларга ашлык тутырса, хуҗабикә Тәнзилә апа өй эчендә кайнаша иде.

Гадәттә мал тотучылар, эше күп, ә табышы аз, диярге ярата. Бу гаиләдә алай түгел. Әлегә сөтнең бер литрын 18 сумга тапшыралар икән. Тик, бәясе арзан, дип зарланмыйлар. Җыючысы булганга шөкер итәләр, киләчәктә артыр, дип өметләнәләр. Көнгә 100–120 литр сөт тапшыру начар күрсәткеч түгел.

– Мәшәкате күп, әмма ашы да әйбәт бит, бәгърем. Асрамасаң, бер нәрсә дә юк. Мал тотсаң, авызың шапылдап тора. Кучтәнәчкә дә бирә аласың. Авылда да тәмле ашап, матур киенеп, бик әйбәт яшәргә мөмкин. Тырышырга гына кирәк, – ди Тәнзилә апа.

Менә нәкъ аларча. Тир түккәч, ике катлы йорт та хыялда гына калмаган. Өйләрен дә курчактай итеп бик матур киендергәннәр. Хуҗабикә үзе дә фырт йөрергә ярата. Китапханәче булгач, зәвыкны сакларга кирәк шул. Бу өлкәдә 38 ел хезмәт итә икән инде. Шул ук вакытта абзардагысын да тәртиптә тотасы. Билгеле, җитеш тормыш күктән генә төшмәгән. Моның өчен йокыдан сәгать 4–5тә торып, көн буе тир түгәргә туры килә.

– Сыер сава белми идем, кияүгә чыккач өйрәндем. Каенанам Разыя авыргач, эре малны бетергәннәр. Башта бер сыер алдык, аннан өчәү булды. Барысын да кул белән саудым. 2000 нче елларда абзарны зурайтып, сыерларны сигезгә җиткездек. Сигез сыерның сигез бозавы туа. Бу – үзе байлык. Заманында утызар баш терлек тоттык. Хәзер үгез, бозаулар белән барысы – 15 баш. Ел саен 70 чеби, 35 үрдәк, 25 каз асрыйбыз, – ди Тәнзилә ханым.

Шул ук вакытта хуҗабикә үзенең тормышта эш мәсьәләсендә нәфеслерәк икәнлеген дә яшерми. «Миңа һәрчак күп кирәк булды», – ди, елмаеп. Дәү әти, дәү әни тәрбиясендә үскән кыз бу хиснең өйдәгеләреннән күчүен әйтә. Ни өчен дигәндә, алар бик тырыш булган. Сугыштан кайткан бабасы – тормыш тоткасы. 25 баш умарта тоткан, яшелчә, җиләк-җимешне дә мулдан утырткан. Утыз төп алмагач үскән бакчада. Бабасы белән бергәләп 50шәр банка компот япканнар. Менә шундый гаиләдә ялкау булып үсеп була димени?!

– Басуда хатыннар белән чөгендер алабыз шулай. Мин унсигезенче чөгендерне чистартканда, берсенең кулында беренчесе генә иде. Шуннан теге җиде хатыннан аерым эшләргә булдым. Карасам, берүземә 12 трактор чөгендер китереп бушатканнар. Бер атнада җиде «КамАЗ» төяп җибәрдем. Теге хатыннарның исә барысының эшләгәне шуның кадәр. Әлеге акчага җиде капчык шикәр комы алдым. Менә шуннан көчемне чамала инде, – дип көлә Тәнзилә апа.

Хуҗабикә әйтүенчә, терлек асрамасалар, мондый тормыш мәңге тәтемәс иде. Сөттән каймагын, сырын, эремчеген, кортын ясый. Күрше авыл халкы да, шулай ук шәһәрдән кайтучылар да товарын сорап тора икән. Кортның килосы – 500 сум. Базарда 11 ел ит сатканнар.

Әле бит сатканчы, башта үстерергә кирәк. Элегрәк ике улы, ире болында көн саен бер йөк машинасы печән чапкан. Хәзер терлек азыгын сатып алалар. Кергән акчага исә улларын Казан дәүләт төзелеш-архитектура институтында укытканнар. Ул заманда елына 46 мең сум акча түләп укыту җиңел булмаган, билгеле. «Акчаны әрәм-шәрәм итмәдек. Балалар укытканда, затлы туннар кия алмадым. Терлек суйган акчаны тизрәк кассага илтеп сала идек. Һәр тиеннең кадерен белдек», – ди әңгәмәдәшем.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хәзер инде бар да җитеш. Олы улы Рәфыйк Казанда гомер итә. Төпчек улы Булат, өйләнеп, гаиләсе белән төп йортта яши. Ул коткаручы булып эшли. Тәүфыйк абый, инвалид булса да, абзарда терлек карарга булыша. «Өйдә көн буе телевизор карап, диванда яту эш түгел, маллар янында рәхәт», – ди икән. Гаилә алга карап, сыерлы көнем – сыйлы көнем, дип, өмет белән яши.

Сәрия МИФТАХОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 20 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 4; 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы Конституциясе һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең хокукый нигезләрен билгели.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы – Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары структурасына кертелгән, үз компетенциясе чикләрендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы һәм шушы максатларда Татарстан Республикасы карамагындагы эшләр, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы эшләр буенча вәкаләтләр, шулай ук Россия Федерациясенең тапшырылган аерым вәкаләтләре бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт органы;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы – билгеләнгән компетенция чикләрендә эшчәнлеге дәүләт идарәсен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең килешеп эшләүче һәм үзара хезмәттәшлек итүче органнары җыелмасы;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары структурасы – Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Рәисе актлары нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары исемлеге;

4) республика башкарма хакимият органнары – министрлыклар, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ведомство буйсынуындагы башка Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары;

5) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы компетенциясе – Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының дәүләт идарәсенең билгеле бер функцияләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләре җыелмасы;

6) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләре – Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының үз эшчәнлеге өлкәсендә хокукый актлар кабул итүгә, шулай ук башка дәүләт-хакимият гамәлләрен башкаруга карата хокуклары һәм бурычлары.

2. Әлеге Законда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» һәм «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» төшенчәләре бер үк мәгънәдә кулланыла.

3 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең хокукый нигезләре**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыралар.

4 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары системасын Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, министрлыклар, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары һәм башка Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тәшкил итә.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләнә.

5 статья. **Татарстан Республикасы Рәисе**

1. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә дәүләт башлыгы, Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты була һәм Татарстан Республикасында башкарма хакимияткә җитәкчелек итә.

2. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә сайлана һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында тантаналы шартларда ант иткәннән башлап вәкаләтләрен үтәүгә керешә.

3. Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләре Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы шартнамәләре һәм килешүләре белән билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы Рәисе, федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә, Россия Федерациясенең тапшырылган аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органы структурасын раслый.

5. Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый актлары аларны имзалаганнан соң 14 көн эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрелә.

6 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты иң югары даими эшләүче Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы була.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан төзелә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Рәисе алдында җаваплы була.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары үтәлешен һәм республика башкарма хакимият органнарының килешенгән эшчәнлеген тәэмин итә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибе, вәкаләтләре Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка законнары, федераль башкарма хакимият органнары белән килешүләр, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына федераль башкарма хакимият органнарының аерым вәкаләтләрен тапшыруны күздә тоткан Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте», «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты», «Татарстан Республикасы Хөкүмәте» исемнәренең мәгънәләре бертөрле була.

7 статья. **Республика башкарма хакимият органнарына карата Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты республика башкарма хакимият органнарының эшен берләштерә һәм аңа юнәлеш бирә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз компетенциясе чикләрендә:

1) республика башкарма хакимият органнары турындагы нигезләмәләрне раслый, аларның хезмәткәрләренең иң чик санын билгели;

2) әлеге Законның 5 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, республика башкарма хакимият органы структурасын раслый;

3) республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре урынбасарларын вазыйфаларына билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә;

4) республика башкарма хакимият органнары коллегияләре составларын раслый;

5) республика башкарма хакимият органнары актларын гамәлдән чыгарырга яисә мондый актларның гамәлдә булуын туктатып торырга хокуклы була;

6) Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, федераль башкарма хакимият органнары белән килешүләр, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына федераль башкарма хакимият органнарының аерым вәкаләтләрен тапшыруны күздә тоткан Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

8 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составы һәм структурасы**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Премьер-министрыннан, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларыннан, Татарстан Республикасы министрларыннан, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары рәисләреннән тора.

2. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары җитәкчеләрен кертә ала.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының вазыйфалар буенча составы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

4. Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән килештереп, Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләп куела.

5. Татарстан Республикасы Премьер-министры кандидатурасы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына килештерүгә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яңа сайланган Татарстан Республикасы Рәисе алдында үз вәкаләтләрен туктатканнан соң яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йә Татарстан Республикасы Премьер-министры отставкасыннан соң 30 көннән дә соңга калмыйча кертелә.

9 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре срогы**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләре срогы чикләрендә гамәлдә була һәм яңа сайланган Татарстан Республикасы Рәисе алдында үз вәкаләтләрен туктата. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының үз вәкаләтләрен туктатуы турындагы карар Татарстан Республикасы Рәисе үз вазыйфасына керешкән көнне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән рәсмиләштерелә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, үз вәкаләтләрен туктаткан очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының яңа составы төзелгәнче эшләвен дәвам итә.

10 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты отставкасы**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты отставка сорарга мөмкин, аны Татарстан Республикасы Рәисе кабул итә яисә кире кага.

2. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты отставкасы турында карар кабул итә ала.

3. Татарстан Республикасы Рәисен федераль законда билгеләнгән тәртиптә вазыйфасыннан читләштерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының отставкага китүенә китерә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, отставкага киткән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының яңа составы төзелгәнче эшләвен дәвам итә.

11 статья. **Татарстан Республикасы Премьер-министры вазыйфаларын башкару**

1. Татарстан Республикасы Премьер-министры эш урынында вакытлыча булмаган очракта, аның вазыйфаларын Татарстан Республикасы Премьер-министры яисә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләнә торган аның урынбасарларының берсе башкара.

2. Татарстан Республикасы Премьер-министры вазыйфасыннан азат ителгән очракта, Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры билгеләп куелганчы, Татарстан Республикасы Премьер-министры вазыйфаларын башкаруны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларының берсенә йөкләргә хокуклы.

12 статья. **Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының башка әгъзалары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Премьер-министры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты рәисе була һәм аның эшен оештыра.

2. Татарстан Республикасы Премьер-министры, билгеләп куелганнан соң җиде көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Рәисенә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы буенча тәкъдимнәр кертә.

3. Татарстан Республикасы Премьер-министры:

1) Татарстан Республикасында һәм аннан читтә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән эш йөртә;

2) Татарстан Республикасы Рәисенә Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының башка әгъзаларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына кермәгән республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләрен вазыйфаларына билгеләп кую һәм вазыйфаларыннан азат итү турында тәкъдимнәр кертә;

3) Татарстан Республикасы Рәисенә республика башкарма хакимият органнарын төзү, аларның исемнәрен алмаштыру, аларны үзгәртеп кору һәм бетерү турында тәкъдимнәр кертә;

4) хәлиткеч тавыш хокукына ия булып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм аның Президиумы утырышларын алып бара;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларын имзалый;

6) Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары арасында вазыйфаларны бүлә;

7) үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзаларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләрен һәм Татарстан Республикасы Премьер-министрына буйсынган башка вазыйфаи затларны бүләкләү һәм аларга дисциплинар җәза бирү турында карарлар кабул итә;

8) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

4. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары:

1) хәлиткеч тавыш хокукы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында катнашалар;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашалар;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелгән тәкъдимнәрне, карарлар һәм күрсәтмәләр проектларын алдан карыйлар;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын әзерләүдә катнашалар, аларның үтәлешен тәэмин итәләр;

5) вазыйфалар бүленеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларының һәм күрсәтмәләренең үтәлешен тикшереп торалар;

6) вазыйфалар бүленеше нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының башка әгъзалары:

1) хәлиткеч тавыш хокукы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында катнашалар;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын әзерләүдә катнашалар, аларның үтәлешен тәэмин итәләр;

3) әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

13 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты оператив мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумын төзи, аның составына вазыйфалары буенча Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары, шулай ук башка затлар да керергә мөмкин.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы утырышлары кирәк булган саен уздырыла.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы карарлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы әгъзаларының гомуми санының күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларына каршы килмәскә тиеш.

4. Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумының теләсә кайсы карарын гамәлдән чыгарырга хокуклы.

14 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышлары**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзалары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында шәхсән катнашалар.

2. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Югары Суды, Татарстан Республикасы Арбитраж суды, Татарстан Республикасы прокуратурасы, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Советы» Ассоциациясе вәкилләре, башка затлар законнар нигезендә йә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында катнашырга хокуклы.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында Татарстан Республикасы Премьер-министры яисә Татарстан Республикасы Рәисе рәислек итә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты аерым мәсьәләләрне ябык утырышларда карый, шулай ук утырышлар чакырмыйча гына карарлар кабул итә ала.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларын әзерләү һәм үткәрү, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карарлар әзерләү һәм аларны утырышлар чакырмыйча гына кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

15 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында карала торган мәсьәләләр**

1. Түбәндәге мәсьәләләр бары тик Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында гына карала:

1) Татарстан Республикасы бюджеты проекты турында;

2) Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе проекты турында;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы составы турында;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты турында;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында.

2. Башка мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән очракларда, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе яисә Татарстан Республикасы Премьер-министры карары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламентында билгеләнгән тәртиптә каралырга мөмкин.

16 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисе указлары нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара, аларның үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итә.

2. Норматив характердагы актлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары рәвешендә чыгарыла. Оператив һәм башка агымдагы мәсьәләләр буенча норматив характерда булмаган актлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәләре рәвешендә чыгарыла.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларын кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты белән билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм күрсәтмәләрен Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәү мәҗбүри.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә таратылырга тиеш булмаган башка белешмәләр булган карарлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе Татарстан Республикасы законы нигезендә билгеләнә.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары аларны чыгарган көннән алып 14 көн эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрелә.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хокукый характерда булмаган мөрәҗәгатьләр, белдерүләр һәм башка актлар кабул итәргә хокуклы.

17 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеген тәэмин итү һәм республика башкарма хакимият органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кабул иткән карарларның үтәлешен тикшереп торуны оештыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты төзелә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Татарстан Республикасы дәүләт органы була.

3. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына җитәкчелек итә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты турындагы нигезләмә, аның иң чик саны, структурасы һәм штат расписаниесе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты юридик зат була, аның үз балансы, казначылык органнарында шәхси счетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте һәм үз исеме булган мөһере, башка мөһерләре һәм штамплары, бланклары бар.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетында бу максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

18 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында органнар һәм оешмалар төзү**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты дәүләт идарәсенең аерым мәсьәләләре буенча бурычларны килешеп хәл итү, шулай ук үз эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында оешмалар булдырырга, координация органнары, киңәшмә һәм башка органнар төзергә хокуклы.

19 статья. **Республика башкарма хакимият органнары**

1. Республика башкарма хакимият органнарын төзү, аларның исемен алмаштыру, аларны үзгәртеп кору һәм бетерү Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Республика башкарма хакимият органнарын үзгәртеп коруга, бетерүгә бәйле мәсьәләләр, үзгәртеп корыла, бетерелә торган республика башкарма хакимият органнарының функцияләрен һәм вәкаләтләрен тапшыру, хокукый варислык мәсьәләләрен дә кертеп, Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый актлары яисә Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән регламентлаштырыла.

3. Республика башкарма хакимият органының функцияләре, вәкаләтләре, эшчәнлек тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган тиешле республика башкарма хакимият органы турындагы нигезләмә белән билгеләнә.

4. Республика башкарма хакимият органнарының функцияләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы нигезендә билгеләнә.

5. Республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфаларына билгеләп куела һәм вазыйфаларыннан азат ителә.

6. Республика башкарма хакимият органы юридик зат хокукларына ия була, аның казначылык органнарында шәхси счетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте һәм үз исеме булган мөһере, башка мөһерләре һәм штамплары, бланклары бар.

7. Юридик зат хокуклары республика башкарма хакимият органы структурасына мөстәкыйль бүлекчәләр буларак кергән Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, ә аерым очракларда республика башкарма хакимият органының территориаль органнарына бирелергә мөмкин.

8. Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетында бу максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

9. Республика башкарма хакимият органнары аларның эше өчен кирәкле мөлкәт – биналар, элемтә чаралары, техник җиһазлар, транспорт чаралары һәм башка матди-техник чаралар белән тәэмин ителә.

10. Мөлкәтне республика башкарма хакимият органына беркетү турында карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йә Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт белән идарә итүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан кабул ителә.

11. Республика башкарма хакимият органнарына беркетелгән мөлкәт Татарстан Республикасы милке була һәм аларның оператив идарәсендә тора.

12. Республика башкарма хакимият органын бетерү аны граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак бетерүгә китерә.

Ахыры 4 нче биттә >

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең бүлек мөхәррире **Әхмәтҗанова** Фәния Кәбир кызы, күпьеллык намуслы хезмәте, актив иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге өчен «АК БАРС СОЗИДАНИЕ» хәйрия фонды директоры **Вәлиева** Әлфия Фуат кызы, республиканың агросәнәгать комплексына югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең физика һәм математика кафедрасы мөдире **Ибәтов** Равил Ибраһим улы, торак-коммуналь хуҗалык тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Районны төзекләндерү һәм агачлар-үсемлекләр утырту + К» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Матросова** Кәүсәрия Ильяс кызы, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм юл төзелеше тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Татавтодор» акционер җәмгыяте Апас филиалының асфальт-бетон заводы төзү эшләре җитәкчесе **Миңнуллина** Лира Рәшит кызы, республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Заря» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Буа районы) **Мөдәрисов** Фәрид Җәмил улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Милләтләр арасында татулыкны һәм тынычлыкны ныгытуга, татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Кострома шәһәренең мөселман дини берләшмәсе» җирле дини оешмасы рәисе **Сәйдәшев** Ришат Рәшит улы, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе, актив иҗтимагый эшчәнлеге һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Бөтенроссия Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы сукырлар җәмгыяте» инвалидларның гомумроссия иҗтимагый оешмасы Татарстан төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Федорина** Нурия Шәйхелислам кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Чишмәойл» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте «Чишмәойл» акционер җәмгыятенең нефть һәм газ чыгару цехы баш инженеры **Миронов** Сергей Николаевичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе «Нурлат-нефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе 1 номерлы нефть һәм газ чыгару цехы башлыгы **Моратов** Фәнис Хафиз улына **«Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, республикада физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен **«Татарстан Республикасы «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый-дәүләт оешмасы** коллективына, физик культураны һәм спортны үстерүгә, динамо хәрәкәтен популярлаштыруга зур өлеш кертүләре өчен «Татарстан Республикасы «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый-дәүләт оешмасы хезмәткәрләре: система администраторы **Гыймадиев** Вадим Равил улына, кадрлар бүлеге инспекторы **Гыйниятуллина** Венера Рөстәм кызына, баш бухгалтер **Синенко** Людмила Владимировнага, республикада ветераннар хәрәкәтен үстерүдәге казанышлары, яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүгә зур өлеш кертүләре һәм актив иҗтимагый эшчәнлекләре өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) иҗтимагый оешмасы рәисе **Скоков** Александр Алексеевичка, Казан шәһәре Киров районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе **Снегирева** Гөлсирә Әхмәтҗан кызына, «Россия ветераннар берлеге» Бөтенроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасы Координация советы рәисе **Юлашев** Әхәт Гайнулла улына **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

20 статья. **Республика башкарма хакимият органнары актлары**

1. Республика башкарма хакимият органнары үз компетенциясе чикләрендә үзләре карамагындагы мәсьәләләр буенча норматив хокукый актлар, шулай ук тиешле республика башкарма хакимият органының ведомство буйсынуындагы барлык оешмалар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмә бирү актлары чыгаралар. Республика башкарма хакимият органы тарафыннан чыгарыла торган актларның төрләре әлеге орган турындагы нигезләмәдә билгеләнә.

2. Федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда республика башкарма хакимият органнары үз компетенциясе чикләрендә башкарма хакимиятнең башка органнары, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле норматив хокукый актлар, шулай ук гомуммәҗбүри характердагы норматив хокукый актлар чыгарырга хокуклы.

3. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

4. Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт теркәвенә алынган норматив хокукый актлары, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә таратылырга тиеш булмаган башка белешмәләр булган актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

5. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары аларны дәүләт теркәвенә алган көннән алып 14 көн эчендә республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрелә.

21 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән хезмәттәшлеге**

1. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан куелган мәсьәләләр буенча, еллык хисаплар, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында җыелма еллык доклад тәкъдим итә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәсе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы таләбе буенча йә үз инициативасы белән законнар проектларын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектларын эшләүне оештыра һәм аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, республика башкарма хакимият органнары үз инициативасы белән яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы һәм комитетлары таләпләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына ул карый торган законнарга һәм законнар проектларына рәсми бәяләмәләр җибәрә ала. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәсми бәяләмәләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри каралырга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының башка әгъзалары яисә алар вәкаләт биргән затлар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм ул төзегән органнар утырышларында киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашырга хокуклы.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты керткән закон проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советында һәм ул төзегән органнарда тәкъдим итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәсми вәкиле (рәсми вәкилләре) билгеләнә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы билгеләгән срокта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы алдында үз эше турында хисап бирә.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 май
№ 35-ТРЗ

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 20 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлештә:

а) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары төзү, елга портлары территорияләрен булдыру һәм киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү өчен Россия Федерациясе Урман кодексының 9 статьясы нигезендә гражданнарга, юридик затларга урман фонды җирләре чикләрендә урнашкан урман кишәрлекләрен бирү;»;

б) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өлкәсендәге органының федераль дәүләт урман контролен (урман күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген һәм урманнарны саклауны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү;»;

2) 3 өлештә:

а) 1 пунктта «89 статьясындагы» сүзләрен «81 статьясындагы 18^2 пунктында, 89 статьясындагы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 9 пунктта җөмлә башына «Россия Федерациясе Урман кодексының 81 статьясындагы 18^1 пунктында,» сүзләрен өстәргә;

в) 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урманнарны саклауны гамәлгә ашыру;»;

г) 13^4 пунктта «3 өлеше» сүзләрен «4 өлеше» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге уникенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 8 статьяда:

а) 1 өлештә:

егерме беренче һәм егерме икенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

егерме дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өлкәсендәге органының федераль дәүләт урман контролен (урман күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген һәм урманнарны саклауны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү;»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге икенче – егерменче, егерме җиденче – кырыгынчы абзацларында күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан башкарыла. Әлеге статьяның 1 өлешендәге егерме дүртенче – егерме алтынчы абзацларында күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

3 статья

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «а» һәм «б» пунктчалары 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 май
№ 36-ТРЗ

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 20 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 3 пунктында «һәм эшлекле» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 10 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, дәүләт хезмәте яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына, профессиональ дәрәҗәгә, шулай ук яллаучы вәкиленең тиешле карары булган очракта – белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең гомумиләштерелгән төркемнәренә), яңадан һөнәри әзерләүнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә карата квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә.»;

б) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Профессиональ дәрәҗәгә карата квалификация таләпләре дәүләт хезмәте вазыйфаларының категориясенә һәм төркеменә, дәүләт хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә бәйле рәвештә дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи регламентында билгеләнә. Дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи регламентында (алга таба – вазыйфаи регламент) шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең гомумиләштерелгән төркемнәренә), яңадан һөнәри әзерләүнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә карата дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен кирәкле квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 12 һәм 13 өлешләр өстәргә:

«12. Дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданны яисә дәүләт хезмәткәрен дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү, Федераль законда башкасы каралмаган булса, дәүләт органының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре бүлекчәсе (алга таба шулай ук – дәүләт органының кадрлар хезмәте) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

13. Дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданны яисә дәүләт хезмәткәрен профессиональ дәрәҗәгә карата квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү максатларында дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан әлеге гражданның яисә дәүләт хезмәткәренең дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен профессиональ дәрәҗәсен бәяләү гамәлгә ашырыла. Профессиональ дәрәҗәне бәяләү, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килмәгән бәяләү алымнарын кулланып, дәүләт органының тиешле вазыйфа булдырылган бүлекчәсе һәм дәүләт хезмәте белән идарә итү органы катнашында гамәлгә ашырыла. Дәүләт органы җитәкчесе яисә ул вәкаләт тапшырган зат карары нигезендә профессиональ дәрәҗәне бәяләүгә дәүләт хезмәткәрләренең профессиональ хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә һәм төрләрендә яисә кадрлар технологияләре һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча махсуслаша торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар, шулай ук аларның вәкилләре җәлеп ителергә мөмкин.»;

3) 11^1 статьяның 4 өлешендә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

4) 11^2 статьяда:

а) 5 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 17 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Дәүләт хезмәткәренә класслы чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 16 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, класслы чиннар бирергә вәкаләтле органга яисә вазыйфаи затка барлык кирәкле документлар белән бергә класслы чин бирү турында тәкъдим керткән көннән бер айдан да соң булмаган срокта кабул ителергә тиеш.»;

в) 18 өлештә «квалификация имтиханын уздырмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 15 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктта «квалификация дәрәҗәсен» сүзләрен «профессиональ дәрәҗәне» сүзләренә алмаштырырга;

6) 20 статьяда:

а) 1 өлештә «һәм дәүләт органы административ регламентының бер өлеше булып торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Вазыйфаи регламент нигезләмәләре дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм дәүләт органының кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәргәндә, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфасына конкурс үткәрмичә билгеләп куйганда, аттестация үткәргәндә, дәүләт хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлеген һәм аны профессиональ үстерүне планлаштырганда исәпкә алына.»;

в) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи регламентны үтәве ул дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашканда яисә дәүләт органының кадрлар резервына кертелгәндә, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфасына конкурс үткәрмичә билгеләп куелганда, аттестация үткәргәндә йә бүләкләгәндә аның профессиональ хезмәт эшчәнлеген бәяләгәндә исәпкә алына.»;

7) 21 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Аттестация дәүләт хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлеген бәяләүне һәм аның профессиональ дәрәҗәсен бәяләүне үз эченә ала.»;

8) 22 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

9) 34 статьяда:

а) 1 өлештә:

1 пунктта «һәм эшлеклелек сыйфатларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта «һөнәри осталыгын» сүзләрен «профессиональ дәрәҗәсен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең 5 пунктында «яисә белгечлек имтиханы» сүзләрен төшереп калдырырга;

10) 36 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт хезмәткәренең һөнәри үсеше дәүләт хезмәткәренең профессиональ дәрәҗәсен тәэмин итүгә һәм арттыруга юнәлдерелгән, һәм аңа өстәмә һөнәри белем алу һәм һөнәри үсеш буенча башка чаралар керә.»;

11) 41 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 пунктта «составын» сүзеннән соң «, кадрларны эзләүне һәм җәлеп итүне, дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүчеләрнең профессиональ дәрәҗәсен бәяләүне, дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүне тикшерүне дә кертеп,» сүзләрен өстәргә;

б) 11 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 май
№ 37-ТРЗ

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 20 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 33 статьясындагы 3^4 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), «түләү» сүзен «түләү алу, мондый юллардан, мондый участоклардан ташламалы йөрүне яисә мондый юллардан, мондый участоклардан түләү алмыйча гына йөрүне бирү тәртибе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 май
№ 38-ТРЗ

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 20 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 бүлегенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 27 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 10^6 статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«10^6 статья. **Депутатларның аларны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында үзләренә нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү тәртибе**

1. Коррупциячел хокук бозу кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) ирекле формада язмача әзерләнә.

2. Хәбәрнамәдә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

а) хәбәрнамә тапшырган депутатның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта);

б) хәбәрнамә тапшырган депутатның яшәү урыны, телефоны;

в) депутатка аны коррупциячел хокук бозу кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү датасы, вакыты, урыны һәм рәвеше турында мәгълүмат;

г) депутатны коррупциячел хокук бозу кылуга тарту алымы (акча тәкъдим итү, янау, вәгъдә бирү, алдалау, көч куллану һәм башка алымнар);

д) депутат җәлеп ителгән коррупциячел хокук бозу билгеләре булган гамәлләрне (гамәл кылуны яисә гамәл кылмауны) җентекләп тасвирлау;

е) депутатны коррупциячел хокук бозу кылуга тарткан зат (затлар) турында барлык билгеле белешмәләр;

ж) хәбәрнамәгә имза кую датасы;

з) хәбәрнамә тапшырган депутатның имзасы.

3. Хәбәрнамәгә депутатны коррупциячел хокук бозу кылуга тарту максатларында аңа нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү рәвешен раслый торган барлык булган материаллар өстәп тапшырыла.».

2 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 9^2 статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«9^2 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның аларны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында үзләренә нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затлар (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларыннан тыш) аларны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында үзләренә нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итүе турындагы барлык фактлар хакында шундый мөрәҗәгать булган көннән алып биш көн эчендә прокуратура органнарына яисә Татарстан Республикасы Рәисе администрациясенә хәбәр итәргә тиеш.

2. Коррупциячел хокук бозу кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү факты турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) ирекле формада язмача әзерләнә.

3. Хәбәрнамәдә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) хәбәрнамә тапшырган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта);

2) хәбәрнамә тапшырган зат били торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасының тулы исеме, әлеге затның яшәү урыны, телефоны;

3) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка аны коррупциячел хокук бозу кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү датасы, вакыты, урыны һәм рәвеше турында мәгълүмат;

4) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затны коррупциячел хокук бозу кылуга тарту алымы (акча тәкъдим итү, янау, вәгъдә бирү, алдалау, көч куллану һәм башка алымнар);

5) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат җәлеп ителгән коррупциячел хокук бозулар билгеләре булган гамәлләрне (гамәл кылуны яисә гамәл кылмауны) җентекләп тасвирлау;

6) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затны коррупциячел хокук бозу кылуга тарткан зат (затлар) турында билгеле булган барлык белешмәләр;

7) хәбәрнамәгә имза кую датасы;

8) хәбәрнамә тапшырган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның имзасы.

4. Хәбәрнамәгә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затны коррупциячел хокук бозу кылуга тарту максатларында аңа нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү рәвешен раслый торган барлык булган материаллар өстәп тапшырыла.».

3 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 май
№ 39-ТРЗ

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 20 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 өлешнең 1 пунктында «арендалана торган» сүзләреннән соң «күчемле һәм» сүзләрен өстәргә;

2) 4^1 өлештә «арендалана торган» сүзләреннән соң «күчемле һәм» сүзләрен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлектәге 4^3 өлеш өстәргә:

«4^3. Татарстан Республикасы милкендәге арендалана торган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан, мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырып, «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159- ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә сатып алына торган мөлкәт өчен кичектереп түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен сигез елдан һәм күчемле мөлкәт өчен өч елдан гыйбарәт була. Арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектына сатып алына торган арендаланучы мөлкәт өчен түләү тәртибен (берьюлы яисә кичектереп түләү), шулай ук әлеге өлеш нигезендә билгеләнгән чикләрдә кичектереп түләү срогын сайлау хокукы бирелә.».

2 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 4^3 өлеше нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары белән элегрәк төзелгән Татарстан Республикасы милкендәге арендалана торган мөлкәтне сату-алу килешүләреннән килеп чыккан хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 май
№ 40-ТРЗ

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 20 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 1 өлештә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең региональ комплекслы планын әзерләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели, шулай ук күрсәтелгән планны раслый;»;

түбәндәге эчтәлекле 2^1 пункт өстәргә:

«2^1) халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең региональ стандартын раслый;»;

б) 2 пунктның 2 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

2) 4 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органы тарафыннан раслана торган даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын әзерләү тәртибен билгелиләр;».

2 статья

Әлеге Закон 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 май
№ 41-ТРЗ

ВЕТЕРАН ШАТЛЫГЫ

Буада яшәүче Рәүф Төхфәтуллин Җиңү көненә әзерләнә. Хәлләрен белер өчен, өй телефонына шалтыраттык. Трубканы көр тавышлы бер егет алды. «Рәүф абыйны чакырыгыз әле», – диюемә, «Мин бит инде ул», – дип җавап бирде. Сокланып куйдым. 103 яшеңдә егетлекне саклап кара әле син! Сөйләшеп киткәч, тагын бер кат гаҗәпләндем. Берьялгызы гомер итә, тормышны гөрләтеп алып бара! Аллаһы Тәгалә гомерне генә түгел, аңны, зиһенне, акылны өеп биргән аңа.

– Чын яшемне әйтсәм, тагын аптырарсың инде, кызым. Әнием сөйләвенә ышансаң, мин 1919 елның 15 октябрендә туганмын. Армиягә соңрак барсын дип, 1920 елның 5 гыйнвары дип яздыртканнар. Язмыш үзенекен итте, мин гомеремнең 28 елын хәрби хезмәткә багышладым, – дип сөйләп китте Рәүф абый.

Сугыш ачысын күрсә дә, яраткан кешесен югалтса да, ул үзендә яшәр көч тапкан. Күз тимәсен, күңелендә дәрт-дәрман ташып тора әле. Зарланмый, тормышны яратып яши. Шушы көннәрдә Буа районы башлыгы Рәнис Камартдинов бәйрәм белән котлаган.

– Кичә район мәдәният йорты хезмәткәрләре өйгә килеп концерт куеп киттеләр. Әй, күңелле дә булды инде. Яшьлеккә кайткандай булдым. Җиңү җырлары яңгырады бит. Бик тә күңелем булды. Үземә булган игътибардан күзләр яшьләнде. Тикмәгә генә озын гомерле булмаганмын икән. Бар кадер-хөрмәт картлыкка калган, – ди ветеран.

Рәүф абый башта армиядә була. Аннары хәрби училище тәмамлый. Сугыш башланганда, Белоруссиядә була ул. Пулетметчы булып хезмәт итә. Рәүф абый сугышны башыннан алып ахырына кадәр кичә. Җиңүдән соң да тиз генә туган якларына әйләнеп кайта алмый әле ул. Гомеренең 28 елы хәрби хезмәттә үтә.

Хәләл җефете белән сугыш беткән елны очраша. Ул чакта Ольга иреннән аерылган, ике кызы була. Рәүф абый аны язмышымдыр дип кабул итә.

– Күрдем дә гашыйк булдым. Үземә тиң кеше икәнен аңладым. Аның белән бик рәхәт яшәдек. Уртак балабыз булмады. Укытучы иде хатыным. Миннән өч яшькә олы булса да, Аллаһы Тәгалә аңа да озын гомер бирде. Туксанга җитеп вафат булды. Кызларны үземнеке кебек яраттым. Икесенә дә фамилиямне бирдем. Әтиләре булдым. Олы кызым Динә финанс өлкәсендә эшли, кечесе Валентина медицина юлын сайлады. Әти генә дип торалар, – дип сөйли Рәүф абый.

Берүзе яшәсә дә, ялгыз түгел ветеран. Туганнары, якыннары көн дә хәлен белеп тора. Социаль хезмәткәре бар. Ул, атнага ике тапкыр килеп, бар эшен эшләп китә икән. Хәер, Рәүф абый кеше эшләгәнне көтеп тә тормый.

– Иртәм боткадан башлана. Аның янына гел бер йомырка пешереп куям. Чәй урынына гөлҗимеш төнәтмәсе ясап эчәм. Аннары инде гел йөреп торам. Табиблар миңа хәрәкәттә булырга куша. Шуңа күрә бер дә тик ятмыйм. Гел саф һавада йөрим. Олыгая башлагач, әкренләп тоздан һәм баллы ризыклардан арындым. Күбрәк яшелчә һәм кипкән җимешләр яратам. Җиде сәгать йоклыйм. Башым әйләнеп интектерсә дә, кайчак аяклар сызлап алса да, зарланмыйм әле, йөрәгем нык минем. Шуңа яшимдер инде, – ди ул.

Рәүф абый, яшьләргә Ватанны яратырга өйрәтергә кирәк, ди. Соңгы арада гаиләдә ир-ат тәрбиясе җитми дип борчыла ул. Яшьләрнең туган җир, туган як, ватанпәрвәрлек турында бөтенләй башкача уйлауларын бетерер өчен, очрашуларга да йөри икән. Мәктәп укучылары аның бар тормышын яттан белә. Күкрәгенә таккан һәр медальне ни өчен биргәннәрен дә ятлап бетергәннәр. Рәүф абый аларның барысына да үзенеке кебек озын гомер тели.

– Илең өчен утка-суга керергә әзер торырга тиеш син! Ничә еллар сугышта йөреп тә, гомерең бетмәгәч, исән дә каласың икән. Куркырга кирәкми. Егетләр егет булсын иде ул! Иң мөһиме – физик күнегүләр белән дус булырга кирәк, – ди Рәүф абый. – Илләр тыныч булса, яшәүнең яме тагын да артыр иде. Әмма әле дә зарланырлык түгел тормышыбыз. Безнең буын җирдәге оҗмахны да күреп китә инде. Моның өчен җитәкчеләргә рәхмәт.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

АРБАЛЫ ХАТЫННАР

Җиңү көне

Хәтергә мәңгегә уелып кала торган көннәр була. Җиңү көне, мөгаен, шуларның иң олысыдыр. Ул чакта миңа нибары – 10, энекәшләремә 8 һәм 3,5 яшь булса да, барысы да бүгенгедәй хәтердә.

Иртән йокыдан торгач, гадәттәгечә, өстәл янына йөгерешеп килдек. Кичә көне буе ашалмаган, сабый күңеле могҗиза көтә. Тик могҗиза дигәнең генә ялындыра. Шулай итеп, өстәл өсте буш. Инде, тилмереп, әни кайтканны көтәбез. Аларны, ягъни колхозның барлык хатын-кызларын кичә Коркачыкка җибәрделәр. Колхозның чәчә торган бодай орлыгы яраксыз дип табылгач, шуны «уфалла» арбаларына төяп, алмаштырып кайтырга киттеләр. Коркачык бездән 50 чакрым ераклыкта.

Хәзер «уфалла»ның ни икәнен дә белмиләрдер инде. Гап-гади ике тәгәрмәчле арба ул. Авыл җирендә ул һәркемдә дә була. Ялгыз бер әби яши икән, аның каралтысында балта, көрәк булган кебек, һичшиксез «уфалла»сы да була. Чөнки ансыз яшәү мөмкин түгел. Ул атны да, тракторны да, машинаны да алмаштыра иде. Ләкин атта, машинада утырып барасың, ә «уфалла»ны тартырга кирәк, аерма шунда гына.

Көн матур, кояшлы, җылы иде. Авыл тып-тын, барча хатын-кыз Коркачыкта. Ирләр басуда, балалар мәктәптә. Мин укырга бармаска булдым, чөнки күршеләр бакчаларының байтак өлешен эшкәрткәннәр, ә безнең көрәк тә тыкмаган килеш ята. Әнине эштән калдырмыйлар. Алай да ул ел да, җаен табып, 25 сутый бакчаны берүзе көрәк белән казып чыга, бәрәңгесен утырткач, көрәк белән төбенә өя, көрәк белән ала иде. Шуларны уйлап, ике энекәшне дә ияртеп, өч көрәк белән бакчага чыктык.

Мәктәп бездән ерак түгел иде. Мәктәп ишегалдында байрак күтәреп, барабан сугып йөриләр. Соңгы елларда бәйрәмнәрдә шулай итәләр иде. Шунда классташ малайның мәктәптән абына-сөртенә йөгереп кайтып килүен күрдем. Мәктәптән калгач, күрмәсен, әләкләмәсен дип, куак төбенә ышыкландым. Ул миңа: «Качма, качма, бүген уку юк, бәйрәм бүген! Сугыш беткән, сугыш беткән!!!» – дип кычкырды. Шул сүзләрдән тораташ катып калдык. Баштан яшен сызып үткәндәй булды. Болай булгач, тормыш үзгәрәчәк бит инде!

Иң элек кечкенә энекәш күрәген ташлады. Җитте, әти кайткач, без моны бик тиз бәреп чыгабыз. Әти кайтырга чыккандыр инде, поездга утыргандыр, диештек. Тик әтинең ике елдан артык хәбәре юк иде. Ул арада, шаулашып, мәктәптән балалар кайттылар. Карт-коры урамга чыкты, авыл җанланды, барысы да бербереэн тәбрикли, шатлана, кайсылары елый. Без дә шуларга кушылдык.

Шунда классташ малай килде дә, әйдә, әниләрдән сөенеч алырга барабыз, малайлар киттеләр инде, ди. Мин барырга булдым, энекәшләрдән рөхсәт алып, 3 малай кузгалдык. Ләкин юл дигәнең ач малайларны талчыктыра, без колхоз җирләренең зурлыгын да, барасы чакрымнарның байтак булуын да исәпкә алмаганбыз булып чыкты. Берзаман бер иптәшебез, эчәсем килә дип, кире авылга борылды. Бәлки әйләнеп килер дип, аны бик озак көтеп утырдык әле. Аннары әниләрнең арба эзләре буенча басу юлыннан алга тәпиләргә булдык. Шомлы, тирә-якта ник бер җан әсәре булсын. Тагын 7–8 чакрым ара узылгандыр, бер әби белән кызчык чыбык-чабык төялгән «уфалла» белән урманнан килеп чыктылар. Без алардан, әниләрне күрмәдегезме, дип сорадык.

Бүген әле күрмәдек, диделәр, авылга кермәгез, анда пычрак, аналарыгыз да әйләнеп уздылар, шушында гына көтеп торыгыз, дип киңәш иттеләр. Озак көттек. Ниһаять, борылыштан бер төркем «уфалла» тартып баручы хатын-кыз килеп чыкты. Каршыларына йөгердек, тик анда безнең әниләр юк иде. Без алга атладык, еракта тагын бер төркем күренде, болары безнең әниләр төркеме иде. Әни, мине күргәч, сискәнеп китте.

Каршыларына «сугыш беткән», «сугыш беткән» дип кычкыра-кычкыра йөгердек. Ишеткәннәр икән, тәмам йончыган булсалар да, елмайган иттеләр, әмма туктамадылар. Шунда карыйм: кайсыларының арбасына – бер капчык, ә әнинең арбасына ике капчык ашлык салынган. Нигә алай, дип сорадым. Баксаң, алар ашлык алмаштырырга ике тапкыр барырга тиеш булган икән. Берьюлы икене алып кайтсаң, 2 көн ял бирәбез дип ышандырганнар. Әни бәгырь, бакчаны уйлап, ике капчыкка ризалашкан.

Юл михнәтен җиңеләйтәсе килептер инде, хатыннар үзара сөйләшә, көлешкәндәй итә. Шунда берсе, ирләре әйләнеп кайткан хатыннар бу тәртә арасыннан чыгалар инде, ә безгә күпме өстерәргә язгандыр, дип әйтеп куйды. Ә туктап ял иткәндә икенче бер апа, кибеттә ипи сатачаклар икән, дип сөйли башлады. Икенчесе, сатуын сатарлар, каян акча табарга, колхоз акча түләми, дип әйтеп салды. Хатыннарның яхшыга да ышанасы килә, тик михнәт дигәнең генә итәк чабуыннан тарта.

– Көн саен булмаса да, атна-ун көнгә бер мәртәбә алып ашасак та ярар иде әле… И, хатыннар, ипи турында сөйләшкәч, нәкъ ипи ашаган кебек булды бит әле, әйдәгез кузгалыйк, – диде ипи турында хыялланган апа.

Икенче туктаганда Гөлбикә апа капчык өстенә утырган да йокымсырап киткән. Берзаман урманнан яшьрәк бер кыз чыгып бара, кулында чыбык. Шуны чажчож итеп селтәп килә. Гөлбикә апа күзләрен ачты да:

– Әлфинур, кемне кыйнамакчы буласың? – дип сорады.

– Менә Гитлерны тотканнардыр инде. Аны шушында алып килергә иде дә, бөтен «уфалла»ларны ялгап, шуны җигәргә иде. Мин аны шушы чыбык белән ярыр идем, – диде.

Бичара хатыннар тагын кузгалып китте. Арбалары кырыена чабаталарын бәйләп куйганнар, кайсы яланаяк кайта, кайсы оекбаштан. Үзара авылга кергәндә чабаталарны киярбез дип тә сөйләшеп алалар. Мин сабый кызыксынуы белән: «Нишләп авыл башында гына киясез?» – дип сорадым. Әни: «Колхоз чабата бирми бит ул, 100 чакрым шушындый юлда чабата таралып бетә», – дип әйтеп куйды.

Егетләнеп, әниләрдән сөенче алырга дип чыккан без, ике малай, берзаман бөтенләй хәлсезләндек. Минем классташ башта әнисенең арбасына тагылып барды, аннары аңа да хәле калмады. Минем үземдә дә шундыйрак хәл, күз аллары караңгыланып китә, аяклар атлаганы сизелми. Җитмәсә, әни борыла да карый, борыла да карый. Башны капчыкка терәдем дә ике кул белән чытырдап арбага ябыштым, аяк астына карап бераз барам да саный башлыйм, бер адым, ике, өч, биш, ун, йөз, мең, ике мең, өч мең – үзем ничә адымнан соң ялга туктарлар икән дип уйлыйм. Туктамыйлар, барулары бару, каян килә көч-куәт, үҗәтлек?! Авылга кергәч тә әни: «Өйгә кайт, ял ит», – дип җибәрде. Ә әниләргә бер дә, арыгансыздыр, ашап-эчеп алыгыз, ял итегез, дип әйтүче юк. Алда иң авыры, кызганычы – өйдә өч баланың ике тәүлектән артык ашаганнары юк, әни кайтса, аш пешерер иде, дип көтәләр.

Аш пешерер! Әйтергә генә ансат, он юк, бәрәңге юк, керосин юк, тоз юк, чәй юк, сабын юк, ә аш пешерергә кирәк. Җәй уртасында тирә-якта кычыткан, кузгалак бетте. Сыер, сарык, кәҗә аларны ашамый, без ашап бетердек…

Бу хәлләрдән соң бик күп вакытлар узгач, үзебез башлы-күзле, яшәр почмаклы булгач, әнине Казанга кунакка алып килергә гадәтләндек. Арча поездына утырып аз гына баргач та, әни һәрвакыт: «Коркачыкка җитмибезме әле, якынайгач, әйтерсез», – дип кисәтеп куя иде. Поезд Коркачыкка якынайгач, вагон тәрәзәсе янына килеп баса да, рейхстагны алган солдат кебек, зур горурлык белән Каф тавы сыман биек-текә Казансуның уң як ярына күрсәтеп: «Без менә шуннан «уфалла»га ашлык салып мендек, – дип әйтә. – Казансу аркылы кечкенә генә күпер булган, аны ташу алып киткән иде. Елганың сайрак урынын табып, билгә кадәр чишенеп, «уфалла»ны күтәреп чыктык. Ул чакта тау битен хатын-кызлар сырып алган, тузгыган кырмыска оясына охшап калган иде. Кич белән бер авылга килеп җиттек. Безнең кайсыбызны кая урнаштырдылар. Безгә клубның сәхнәсендә урын бирделәр. Телогрейкаларны җәйдек тә шунда йокладык. Иртән юлга чыктык».

Ул елларда бөтен авырлык хатын-кызлар җилкәсенә төште. Чын мәгънәсендә батырлык, каһарманлык, сабырлык үрнәге алар. Шуңа күрә Казансу елгасының тау битендә, ачлы-туклы килеш «уфалла»га җигелеп, тормышны тарткан хатын-кызларга, арбалы хатыннарга һәйкәл куяр идем. Әгәр кодрәтемнән килсә…

screenshot

Нәсих ШӘЙХЕТДИНОВ

Каеннар шаулый

Мостафа НОГМАН

Андрей Горскийның «Без вести пропавший» картинасы. 1946 ел.

Ал нурларга төренеп, кояш байый,
Үткән юллар килә күңелгә.
Җиңүләрне яулап алган көннәр
Онытылмаслар гомер-гомергә.

Зәңгәр томаннарга күмелеп калды
Без походлар кичкән ул чаклар.
Күптән сүнде Дунай буйларында
Без кабызган очкын учаклар.

Югалтулар алып килде сугыш,
Күпме дуслар кайтмый калдылар.
Шул дусларның йокыларын саклап,
Ак каеннар моңсу шаулыйлар.

Таралыштык илнең кырларына, –
Очрашырбыз микән без тагын?
Сагынам сезне – җиңү юлларыннан
Бергә үткән солдат дусларым!

АРТЫК ТАМАК

Ул көнне кырга төшке аш илтә киткән абыемны әти атка утыртып алып кайтты. Югыйсә аның беркайчан да әтине көтеп калганы юк иде, чөнки эш артыннан эш көтеп кенә тора. Ул көнне үги әни үзалдына усал мыгырданып йөрде: ат тизәгенә барасыгыз бар, алабута урып кайтырга кирәк, бәрәңге бакчасын чүп басып килә, кайда йөри бу мөртәт?

Авыл капкасыннан ат күренгәч, каршыларына чаптым. «Әти, абый кайтмады, абый кайда?» – дип кычкырам. Әти дәшми. Печән төягән арбасына да утырмаган, дилбегәне бер кулына гына тоткан да җәяү кайтып килә. Шулвакыт печән эчендә абыйны күреп алдым. «Абый, әни сине әрли, ник кайтмадың?» – дим. Ул дәшми, аның күзләре йомык иде.

Әти капка төбенә кайтып җиткәч, әниеңне чакырып чыгар дип, мине өйгә кертеп җибәрде. Әни чыкты. «Ач капканы!» – диде әти, бик усал итеп. Ат ишегалдына керде. Әни эшнең нидә икәнлеген бик тиз абайлап алды, күрәсең, абыйны күтәреп керүче әтигә ишекләрне киң итеп ачып торды. Сәкегә китереп салгач, абыйның битенә яулык китереп каплады. Мин аны йоклый дип белдем. Ә әти аның янәшәсенә утырды да башын аска иеп елап җибәрде. «Миңа дип алып килгән күкәйне дә ашамаган, ичмасам. Бәлки, исән калган булыр иде бала».

Икенче көнне абыйны юып, төреп, зиратка алып барып күмделәр. «Синең дә урының шунда, артык тамак», – дип, каты итеп беләгемнән чеметеп алды мине үги әни. Ул вакытта өйдән кешеләр чыгып киткән иде инде.

Миңа ул вакытта 7 яшь кенә иде әле. Үз әниебез иртә үлгән. Аны бөтенләй хәтерләмим. Без өч бала ятим калганбыз. Олы апам миннән 8 яшькә зуррак иде. Аны авылыбызның мәрхәмәтле кешеләре үзләре белән Донбасс якларына, Украинага алып киттеләр. Инде абый да, әти дә калдырып китте. Күрше Шәмсетдин бабай белән Гаффә әби мине үз балаларыдай якын күрә иде. Үги әнинең миңа ыжгырып килгән вакытларын алар йөрәкләре белән сиздеме икән, әллә каян гына килеп чыгалар иде дә кул күтәрергә ирек бирмиләр иде. Аларның өендә җылы, рәхәт иде. Туйганчы бәрәңге, солы кесәле ашадым. Әмма өлкәнәеп килгән улларының сугышта һәлак булганлыгы турында хәбәр килеп ирешкәч, алар икесе дә бик нык бирешгте. Киленнәре дә үзләренә охшаган, мәрхәмәтле иде. Барыбер мине якын итте.

Мин сугышка киткән әтине көттем. Авылга яраланган абыйлар кайта башлады. «Безнең әти дә яраланып кайтса иде», – дип уйлый идем. Әмма ул кайтмады. 1946 елда Сталинград сугышыннан исән кайткан Гыйлемхан абый мине чакырып сөйләгән иде: «Әтиең белән Сталинградта бергә сугышырга туры килде. Андый мәхшәрне Ходай бүтән күрсәтмәсен инде. Исән калмагандыр ул, бичаракай. Соңгы тапкыр окопта бергә яттык. Немецлар белән ике арада бер үлгән ат ята. Кышкы салкын үзәккә үтәрлек. Немецлар да, без дә шул атны күзәтәбез. Алар да ач булгандыр, күрәсең. Без әтиең белән һәм тагын ике егет, шуышып, ат янына киттек. Немецлар атса, шунда үлгән булыр идек. Алар карап тордылар, әмма атмадылар. Без, атны тунап, хәйран гына ит алып килдек. Берзаман, бездән соң озак та үтмәде, ат янына немецлар шуыша башладылар. Хәзер инде аларның чираты иде. Без дә аларга атмадык. Шулай итеп, атның сөякләрен дә калдырмыйча чиратлашып ташып бетердек. Аннан тагын сугышка. Бер каты гына бәрелештә мин әтиеңне югалттым». Гыйлемхан абыйны сугыш беткәннән соң Украинага, бандерачыларны бастырырга җибәрәләр. Ул сугыштан орден-медальләр тагып кайтты.

Үги әни әтине алай көтмәде дә бугай. Сугыштан кайткан абыйлар безнең өйдә еш булалар иде. Анысына мин хөкемче түгел. Ул мине, үзенә комачауламасын дип, авылның бер пәпә-телсез егетенә кияүгә бирергә теләде. Мин, елап, Шәмсетдин бабай килене янына йөгереп кердем. «Зинһар, коткар, идән астында булса да утырырмын, кайда икәнлегемне әнигә генә әйтә күрмә», – дидем. Сания апа: «Идән астында яшиләрмени, мин сине иртәгә үк Казанга җибәрәм, анда үз көнеңне үзең ничек тә күрерсең», – диде. Мин качып кына киемнәремне җыйдым да төнлә чыгып киттем. Таң алдыннан атка утырып, Казанга юл тоттым. 1950 елның язы иде ул. Казанга килеп, эшкә урнаштым. Булачак ирем белән дә шунда таныштым. Өйләнештек. Балаларыбыз туды. Бик матур яшәдек. Инде хәзер оныкларым сөендерә. Тормыш барыбер тигезли.

Гөлсирә СОЛТАНОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

7 нче майда кадерле кодагыебыз Лилиягә 50 яшь тула. Аны матур юбилее белән ихластан тәбрик итәбез. «Кода-кодагый» сүзе күңелгә якын. Ул элеккедән калган «кодалау» дигәнне аңлата. Шөкер, без матур итеп, кода-кодагый, дип әйтәбез. Арабыздагы шушы җылылык гомергә җитсен иде.

Хөрмәтле Лилия кодагый!
«Кодам» дип дәшәм шатланып,
Кодагыйга – изге теләкләр!
Тигезлектә, матур тормышта
Бергә типсен сезнең йөрәкләр.
Кодагыйлы кеше бәхетле ул,
Андыйларга кызыгып карыйлар.
Безне сөендереп торсын иде
Балаларыбыз һәм дә оныклар.

Иң изге теләкләр белән, Наил кодагыз белән Зөбәрҗәт кодагыегыз

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест

vk.com

БЕЛЕМНӘРНЕ ТИКШЕРИК!

Мәктәптә өйрәнгәннәр исегездә калдымы икән? Белемнәребезне тикшереп алыйк әле!

1 Боларның кайсы материк түгел?
а) Көньяк Америка;
б) Евразия;
в) Урта Азия;
г) Африка.

2 Җил ни өчен исә?
а) Җир үз күчәрендә әйләнгәнгә күрә;
б) атмосфера басымы төрле булу сәбәпле;
в) агачлар селкенгәнгә;
г) галәмдә барган процесслар аркасында.

3 Әйләнәнең ике ноктасын тоташтыручы иң озын кисемтә – ...
а) радиус;
б) кисүче;
в) диаметр;
г) орынма.

4 Үсемлекләрдә бара торган төп процесс ничек атала?
а) флуоресценция;
б) соляризация;
в) люминесценция;
г) фотосинтез.

5 Пингвиннар кайда яши?
а) Антарктида;
б) Арктика;
в) Төньяк Америка;
г) Гренландия.

6 Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» әсәренең төп герое:
а) Вәли;
б) Галия;
в) Мәдинә;
г) Искәндәр.

Җаваплар: 1) в; 2) б; 3) в; 4) г; 5) а; 6) б.

Гаҗәеп дөнья

Тутый кош җылы якта яши. Бездә аларны зоопаркларда күреп була. Шулай ук аларны өйләрендә тотучылар да бар. Минем апам Риананың Снежка исемле тутый кошы бар. Ул бик кечкенә, сөйләшми дә. Минем сөйләшә торган попугай күрәсем килә.

Иделия Бәдертдинова, 7 яшь. Актаныш

РАЛИНӘ ИБРАЕВА:
«ТУГАН ТЕЛ» ДӨНЬЯГА ТАНЫТТЫ

Бу көннәрдә Казан кызы Ралинә Ибраева турында ишетмәгән кеше сирәктер. «Туган тел» җырын башкарып, Казахстан жюриен таң калдырды ул! 11 яшьлек җырчы кыз «Qazaqstan Даусы. Балалар» проектының киләсе турына узды. Аның белән сәхнә һәм хыяллар турында сөйләштек.

:: Ралинә, ни өчен Казахстан шоу-проектында катнашырга булдың?
– Узган ел мин Мәскәүдә «Голос. Дети» проектында катнаштым. Катнашучылар арасында Казахстан балалары да бар иде. Алар безгә үзләренең проектлары турында сөйләде. Кастинг игълан ителгәч, гариза биреп карарга булдык. Берникадәр вакыттан соң киләсе этапка узуым турында хәбәр килде. Әзерлеккә бик җаваплы карадым. Бу проектта катнашу миңа бик ошый. Казахстан һәм башка илләрдән килгән күп кенә талантлы балалар белән таныштым. Казахстан бәйгесендә Татарстаныбызны күрсәтүем белән горурланам. Безнең мәдәниятне төрле илләрдәге кешеләрнең дә белүен телим.

:: «Туган тел»не шундый матур җырладың син! Җырны кем сайлады?
– Рәхмәт! Кастинг вакытында без оештыручыларга төрле җыр тәкъдим иттек. Алар минем татар телендә җырлавымны теләде. Без Габдулла Тукай сүзләренә «Туган тел» җырын сайладык, чөнки ул – татар халкының иң танылган җырларының берсе, гимны дип әйтергә була. Мин аны балачактан ук беләм. Миңа проектның дүрт остазы да борылды. Мин казах җырчысы, Казахстанда популяр булган «Ninety One» төркеме солисты Алем командасын сайладым. Ул остазлардан беренче булып борылды. Миңа аның иҗаты бик якын һәм аңлаешлы. Ул – бик сөйкемле җырчы. Хәзер без остазым белән яңа композицияләр әзерлибез.

:: Син ничә яшьтән җырлыйсың инде?
– Мин 4 яшемнән җырлыйм, 5 яшемнән вокал белән шөгыльләнәм. Педагогым – «Ямьле» төркеме солисты Альбина Казыйханова. Татар, инглиз, рус һәм башка телләрдәге җырларны да башкарам.

:: Сәхнә – синең өчен нәрсә ул?
– Сәхнә минем өчен икенче йорт кебек. Анда билгеле бер мохит бар һәм ул миңа бик ошый. Һәр чыгышым белән үз-үземә ышанычым арта. Зур сәхнәләрдә җырларга яратам. Быел миңа «Голос. Дети» проектындагы остазым Егор Крид белән аның Мәскәү һәм Санкт-Петербургтагы концертларында чыгыш ясау бәхете елмайды. Шулай ук Димаш, Ирина Аллегрова, Олег Газманов, Сосо Павлиашвили, Турецкий хоры, Юлия Савичева кебек артистлар белән дә җырлаганым бар.

:: Киләчәктә үзеңне җырчы итеп күрәсеңме?
– Миңа башка төрле иҗади һөнәрләр дә кызыклы. Мәсәлән, дизайнер. Вокалдан тыш, күп вакытымны укуга багышлыйм, яхшы укырга тырышам. Шулай ук йөзү белән шөгыльләнәм, буш вакытымны файдалы һәм актив үткәрергә яратам. Һөнәр сайлау турында уйларга иртәрәктер әле. Ләкин нәрсә белән шөгыльләнсәм дә, аны яратып башкарачакмын.

:: Иҗат юлында синең өчен кем үрнәк булып тора?
– Мине төрле музыка жанрларында җырлаучылар илһамландыра. Һәрберсеннән үзем өчен нәрсә дә булса алырга тырышам. Үзем өчен үрнәк итеп педагогым Альбина Фәзировнаны куям. Ул бик матур җырлый.

:: Ралинә, тамашачы мәхәббәтен яулауның сере нидә дип уйлыйсың?
– Минемчә, тамашачының мәхәббәтен яулау өчен ихластан җырларга, җыр белән яшәргә һәм ачык булырга кирәк. Минем үзенчәлегем табигый булуда дип уйлыйм. Елыйсым килсә, елыйм, көләсем килсә, көләм мин. Мине «кояш» дип атыйлар, исемемнең мәгънәсе дә шуны аңлата.

:: Буш вакытларыңда нәрсәләр белән шөгыльләнәсең?
– Рәсем ясарга, биергә, сәяхәт итәргә, гаиләм һәм дусларым белән вакыт уздырырга яратам.

:: Ә иң зур хыялың нинди?
– Минем хыялларым күп, ләкин иң зуры – популяр җырчы булу. Иҗатым белән тамашачыга җылылык һәм мәхәббәт бүләк итәргә телим.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Ралинә Ибраеваның шәхси архивыннан

Кунагыбыз турында белешмә

- Ралинәгә – 11 яшь;
- Казанның «Унбер» лицеенда 5 нче сыйныфта укый;
- узган ел «Голос. Дети» проектында катнашып, Егор Крид командасына эләккән иде;
- балалар «Евровидение»се финалисты, «Детская Новая волна» проекты ярымфиналисты.

Безгә язалар

РОБОТМЫ, УКЫТУЧЫМЫ?

Бүген мин куркыныч төш күреп уяндым... Имеш, безнең мәктәптә барлык укытучыларны да роботлар алмаштырган икән. Барлык фәннәрне – математика, физика, рус теле, географияне, хәтта татар телен дә роботлар укыта икән. Дәрес темаларын аңлаталар, өй эшләрен сорыйлар, билгеләр куялар, «тимер» тавышлары белән шелтәләп алырга да онытмыйлар. Ярый әле төш озакка сузылмады, куркып уянып киттем...

Түбән сыйныфлардан ук мин, бик теләп, төрле фән олимпиадаларында катнашып килдем. Татар, рус теле һәм әдәбиятлары белән аеруча кызыксындым. Әлбәттә, бу уку елында да мин читтә калмадым һәм, рус теле олимпиадасының район турына катнашканда, безгә бик кызыклы бирем тәкъдим ителде. Биремнәр арасында «Киләчәктә укытучыларны роботлар алыштыра алырмы икән?» дигән сорау бар иде. Бу сорау буенча миңа бик озак уйланып утырырга туры килде, чөнки әлеге мәсьәлә хәзер бик актуаль, фикер йөртергә, чыннан да, вакыт күп кирәк. Менә ни өчен керде миңа бу төш!

Укытучылар алар – саф күңелле, һәрвакытта да балаларга ярдәм кулы сузарга әзер торган, аларны аңлый алган кешеләр. Укытучы хезмәте җиңел түгел дип саныйм, чөнки бу һөнәр үз эченә дәресләр үткәрүне генә түгел, балалар белән уртак тел табуны, алар белән дөрес итеп эш итүне дә ала. Әлбәттә, хәзер технологияләр зур үсеш алды, алар көннән-көн үзгәрәләр, яңарыш кичерәләр. Төрле-төрле ясалма интеллектлы роботлар, машиналар барлыкка килеп тора. Моның белән бергә кешеләр арасында, киләчәктә эш калмаячак, барлык эшләрне дә роботлар башкарачак, дигән сүзләр тарала. Ләкин, ни генә дисәләр дә, укытучы һөнәрен тулысынча роботлар алыштыра алыр дип ышанмыйм.

vk.com

Һәрберебез моны күзәткәндер: укытучылар, яңа тема аңлатканда, үзләренең сөйләменә барлык хискичерешләрен салып, бөтен күңелләрен салып, укучыларга аңларга уңайлырак булсын дип, тормышларыннан мисаллар китереп сөйлиләр. Ә роботта күңел дә, хис-кичерешләр дә юк һәм булмаячак та. Ул бит – бары тик хиссез машина, ә укытучыга шатланырга, борчулы хисләрен күрсәтергә, кирәк чакта ярдәм итәргә, укучысы белән бергә хәтта моңсуланып алырга да кирәк. Аннары роботлар дигәч, тагын бер сорау туа: аларны безнең туган телебездә сөйләшергә өйрәтә алырлармы икән соң, әллә бу турыда уйлаучы да булмасмы?

Олимпиада тәмамланганнан соң да бу мәсьәләгә бәйле фикерләр туа торды. 2023 ел Педагог һәм остаз елы дип игълан ителде. Бу бит очраклы түгел. Җитәкчелек тарафыннан әлеге өлкәдәге проблемаларны күреп, киләчәкне күзаллап, уйлап эшләнгән гамәл. Ник дигәндә, хәзерге яшьләр укытучы һөнәрен өстен күрми, бу юнәлештә уку йортларын тәмамлаганнары да эш урыны итеп мәктәпне сайламый, дип сөйлиләр. Әмма киләчәктә аларның балаларын «металл кеше»ләр укыта башласа, бу хәлгә берсе дә риза булмас иде шул. Шуңа күрә 2023 елда илебездә укытучыларның данын үстерү, бу һөнәрнең дәрәҗәсен күтәрү өчен, төрле чаралар оештырылыр дип көтелә. Тик бер ел белән генә чикләнмәсен, дәвамлы булсын иде бу башлангыч. Ә роботлар беркайчан да укытучыларны алмаштырмасын!

Әдилә САБИРОВА,
Балтач районы Норма урта гомуми белем мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы

Киңәш-табыш

Каникулда нишләргә?

Җәй – һәркем көтеп алган ел фасылы. Бала ялның һәр мизгеленнән файда алсын өчен нишләргә? Җәйге каникулны кызыклы да, файдалы да итеп үткәрү өчен, бездән берничә киңәш.

Гаилә белән ял

Шәһәрдә төрле мәдәни-күңел ачу үзәкләрендә каникул алдыннан мәктәп укучылары өчен махсус программалар әзерләнә. Үзәкләрнең программасы төрле яшьтәге балаларга исәпләнгән. Олылар өчен дә кызыклы булачак. Океанариум, зоопарк, төрле күргәзмәләр, мастер-классларда катнашырга, кинотеатрга барырга була.

Спорт

Саф һавада спорт белән шөгыльләнер өчен шәп вакыт. Үзеңне яңа спорт төрендә сынап карау өчен дә менә дигән мөмкинлек! Хәзер бик күп яңа кызыклы юнәлешләр бар: вейкбординг, серфинг, каноэ һ.б. Җәен су коенырга, йөзәргә, көймәдә йөрергә, урманга барырга, футбол яки бадминтон уйнарга да мөмкин.

Уку

Гадәттә, җәй дәвамында укырга тиешле әдәбият исемлеге бик озын була. Үз көчеңнән килгән һәм үзеңә кызыклы булган әсәрләрне сайлап ал. Бәлки, бу өч, биш, йә аннан да күбрәк китап булыр. Әти-әниләргә җәйге каникулда әлеге әдәбият исемлеген һаман искә төшермәскә кирәк.

Һөнәрләр

Буш вакытта яңа һөнәрләр турында белергә, остаханәләргә барырга, төрле белгечлек вәкилләре белән аралашырга була. Һөнәрләр дөньясына тирәнрәк «чуму» өчен, һөнәри юнәлеш бирүче курслар да бар.

Сәхифәне Ләйсән САФИНА әзерләде

Газетаның киләсе саны 12 майда чыга.

Исеңдә тот!

Имтиханнарга әзерләнәбез

Чыгарылыш сыйныф укучыларының урак өсте. Бик тиздән имтиханнар тапшыру чоры башланачак. Укучыларга үзебездән берничә файдалы киңәш тәкъдим итәбез.

УҢАЙ ФИКЕР ЙӨРТ
Уңай нәтиҗәне күз алдына китерү мөһим. Имтиханны тапшыра алмаячакмын дип уйлама. Үзеңә: «Мин булдырам!» – дип әйт. Үзеңне җиңүче итеп күз алдына китер, шул чагында барысы да яхшы булачак.

ЯТЛАРГА ТҮГЕЛ, АҢЛАРГА
Сорауларга җавапны өйрәнгәндә ятларга түгел, аңлап өйрәнергә тырыш. Сорауларда логик эзлеклелекне тап, өйрәнгәндә төрле ассоциацияләр уйлап чыгар.

ҺӘР СОРАУГА – ПЛАН
Материалның структурасын төзү мөһим. Моның өчен план, рәсем, схемалар кулланырга мөмкин. Алар яхшырак хәтердә кала. Һәрбер сорауга җавапны берничә сүз белән дә әйтеп биреп була. Дәреслекне тулаем укып чыгарга һәм истә калдырырга омтылмаска кирәк.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5313 данә
Гомуми тираж – 14266 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 264

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+